КЕМНЕ КЕМНӘН...
Аз санлы халыклар, кыерсытылган телләрне туплаган Кызыл китап чыгарырга вакыт түгелме?
> 2

НОМЕРДА – ДОКУМЕНТ
Татарстан Рәисе имзалаган яңа законнар
> 3–8

БАТЫР БУЛАТ
Медаль белән бүләкләнүен шактый вакыт үзе дә белмичә йөри ул
> 9

МИЛЛИ АККОРД
«ВТ»ның Татарстанда яшәүче халыкларның милли уен кораллары турында махсус проекты
> 10

ВАТАНЫМ ТАТАРСТАН

1918 елның 12 мартыннан бирле чыга | ИҖТИМАГЫЙ-СӘЯСИ ГОМУМТАТАР ГАЗЕТАСЫ | № 50 (29017) | Шимбә | 8 апрель | 2023 ел

Газета 1968 елда Хезмәт Кызыл Байрагы ордены белән бүләкләнде

www.vatantat.ru /vatanimtatarstan /t.me/vatantat

4604609 000131

Гөлгенә ШИҺАПОВА

СОКЛАНУ ҺӘМ САКЛАНУ

Көн кадагында

Яз үзе генә килми. Елның иң матур фасылына соклану белән бергә, белгечләр саклану турында да онытмаска киңәш итә. Ел башыннан бирле республикада талпан кадалуның 113 очрагы теркәлгән, 91 кеше тычкан бизгәге авыруын эләктергән. Роспотребнадзорның Татарстандагы идарәсендә кеше белән табигать арасындагы мөнәсәбәт турында сөйләделәр.

Кеше сәламәтлегенә зыян салучы бөҗәкләр һәм кимерүчеләр хакында халыкны идарә җитәкчесе урынбасары Любовь Авдонина кисәтте.

– Тычканнар чир таратса да, үзләре авырмый. Татарстанның барлык районнарында да тычкан бизгәге чире йоктыру ихтималы зур. Әлеге авыру гап-гади таләпләрне үтәмәгәндә килеп чыга. Яз җитүгә бакча, урманга чыгабыз. Җыештырганда тычканнар килеп чыгып, аларны кул белән дә тотабыз. Кеше 20 процент очракта авыруны кимерүченең селәгәе, сидеге, нәҗесе аша эләктерә. 80 процент очракта авыру һава һәм тузан аша күчә, – ди Любовь Авдонина.

Татарстанда кимерүчеләрнең 30 төре яши. Аеруча соры тычкан куркыныч. Бездә тычкан бизгәге 1959 елдан бирле теркәлә башлаган. Август, сентябрь, гыйнвар айларында чир йогу куркынычы бик нык арта. Татарстан бу чирне йоктыручылар саны буенча Идел буе федераль округында өченче урында. Бу авырудан вакцина юк. Шуңа да баш санитар табиб урынбасары бик сак булырга киңәш итә.

– Тычкан бизгәге янәшәсендә кимерүчеләр тарата торган туляремия дигән авыру да бар. Әлегә аны йоктыручылар юк. Әмма республиканың 19 районында бу чир таралу ихтималы зур. Моннан ничек сакланып була? Куллар чисталыгын кайгыртып. Кыштан соң җыештырганда аеруча сак булырга, кулга перчатка киярга, авызны битлек белән капларга кирәк. Җыештырганда кигән киемнәрегезне салып ташлагыз. Алайса, бик күпләр шул киеме белән өстәл янына ук утыра, – ди Любовь Авдонина. – Тычканнар ризык күп булганга үрчи. Аларны агулап торабыз. Әмма бөтен республиканы колачлап булмый. Шуңа күрә ризык калдыкларын бөтен җиргә чәчмәскә кирәк. Соңгы вакытта күгәрчен-үрдәкләрне ашата башладылар. Алардан калган ризык тычканга да җитә. Әгәр кинәт хәлсезлек, тән температурасы күтәрелү кебек билгеләр сизсәгез, кичекмәстән табибка барыгыз.

ТАЛПАННАН НИЧЕК САКЛАНЫРГА?

✓Талпан һава торышына карап һөҗүм итә. +7 градустан алып +22 градуска аларга бик уңай һәм бу чорда кешегә кадалулары еш күзәтелә.

✓Бик эсседә алар ял итә. Яңгыр алдыннан, дымлы көннәрдә исә һөҗүмгә әзер торалар. Талпан кадалуның иң куркыныч сәгате иртәнге 8–9 һәм кичке 7 белән 10 арасы.

Илдар Мөхәммәтҗанов

Талпан кадалуның беренче очрагы 25 мартта ук теркәлгән инде.

Талпаннар 25 мартта ук уянган инде. Талпан кадалуның беренче очрагы шул көнне теркәлгән. Татарстанның 30 районында энцефалит таратучы талпаннарны очратырга мөмкин. Әгерҗе, Актаныш, Әлмәт, Саба, Зәй, Спас, Биектау районнарында авыру эләктерү ихтималы зур.

Халык телендә урман бете дип йөртелгән бу бөҗәкләргә тереклек итәр өчен 1 градус җылы да җитә. Алар май аенда үрчи башлый һәм ул июнь аена кадәр дәвам итә. Талпаннар җәен үзен тыныч тота. Бераз кими дә әле. Беренчедән, кешегә кадалгач, инде исән калмыйлар. Икенчедән, эссе һава торышын яратмыйлар. Талпаннар дымлы һәм салкынча вакытта үзләрен яхшы хис итә. Арада октябрь аена кадәр активлыгын саклаучылары да бар.

– Талпаннар җирдән 1,5 метрдан биек булмаган куе үлән арасында яши. Башта кешенең киеменә эләгәләр. Ел саен урман бете кадалуның 10 мең очрагын теркибез. Татарстанда энцефалитлысы теркәлмәсә дә, берничә читтән кергән очрак була. Талпан кадалган кешеләрнең 50гә якынында боррелиоз табылды, – ди Любовь Авдонина. – Без кешегә кадалган һәм үзебез тоткан бөҗәкләрне тикшереп карагач, аларның 32 процентында боррелиоз авыруы барлыгын ачыклыйбыз. Талпаннардан саклану өчен дөрес итеп киенергә, урман-парклардан кайткач киемне кагарга, тәнне тикшерергә кирәк. Шулай ук вакцина ясатырга була.

Көннәр җылыткач, чебен-черкие дә борчый башлый. Роспотребнадзор белгечләре республикадагы 709 сулыкны эшкәртә. Ишегалларын, йорт тирәләрен агулыйм дисәң, моның өчен акча түләргә туры киләчәк. Тычканнарны исә, гариза булганда, бушлай агулап китәләр.

САН

Роспотребнадзорның Татарстан буенча идарәсе мәгълүматларына караганда, бүгенгә республиканың 25 районында талпан кадалуның 113 очрагы теркәлгән. Быелның 3 аенда Татарстанда 91 кеше тычкан бизгәге авыруын эләктергән. Узган ел 844 очрак теркәлгән. Черкиләр дигәннән, республикада 2010 елдан бирле малярия теркәлмәгән. Аның каравы соңгы 13 елда читтән ияреп кайткан 28 очрак билгеле. Узган ел 3 кеше, ял итәргә барып, малярия йоктырып кайткан.

Күбрәк артсын

Татарстанда компьютерлар, электроника һәм оптика җиһазлары җитештерү бер ел эчендә ике тапкыр диярлек (94,5 процентка) арткан. Татарстанстат мәгълүматлары буенча, йорт җиһазлары җитештерү – 1,5 тапкыр, электр җиһазлары – 20 процентка, кием-салым – 18, металлургия производствосы – 15, күн – 12, азык-төлек җитештерү 9,5 процентка үскән.

Моннан тыш автомобильләр һәм җиһазлар, прицеп һәм ярымприцеплар төзекләндерү-монтажлау, әзер металл эшләнмәләр, минераль продукция, кәгазь һәм кәгазь әйберләр эшләп чыгару күрсәткечләре яхшырган.

Шул ук вакытта агач эшкәртү, агачтан әйберләр җитештерү – 36,8 процентка, текстиль әйберләр – 33,4, химик матдәләр һәм химик продуктлар җитештерү 21,1 процентка кимегән. Шулай ук нефть продуктларын, дару, эчемлекләр, резина, пластмасса эшләнмәләр җитештерү, полиграфия эшчәнлеге күрсәткечләре начарайган.

Өметле фаразлар

Россия Авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек министрлыгы быел 120 миллион тонна күләмендә ашлык җыеп алуны күздә тота. Күрсәткеч шәхси ярдәмче хуҗалыкларны исәпкә алмыйча китерелгән.

Шулай ук 2023 елда 24,6 миллион тонна май культуралары, 7,176 миллион тонна бәрәңге, 5,6 миллион тонна яшелчә (кышкы теплицаларда – 1,54 миллион тонна), 1,6 миллион тонна җиләк-җимеш җыеп алу планлаштырылган.

Росстат мәгълүматларына караганда, 2022 елда ашлык уңышы рекордлы күрсәткечкә – 157,7 миллион тоннага (шул исәптән 104,2 миллион тонна бодай) җиткән. Май культураларыннан 29,1 миллион тонна уңыш җыеп алынган. Гомумән, күпчелек культуралар буенча рекордлы күрсәткечләргә ирешелгән. Белгечләр быел уңышның кимрәк булуын фаразлый. Министрлыкта соңгы тапкыр (узган елның декабрендә) 125–127 миллион тонна ашлык (шул исәптән 80–85 миллион тонна бодай) җыеп алу ихтималын әйткәннәр.

Үсемлекчелектән аермалы буларак, терлекчелектә җитештерү планнары узган елгы нәтиҗәләрдән югарырак. Әйтик, терлек һәм кош-кортны – 16,4 миллион тонна (узган елда – 16,2 миллион тонна), сөтне 33,2 миллион тонна (2022 елда – 33 миллион тонна) күләмендә җитештерү күздә тотыла.

Киметәсе иде

Россиядә тәмәке тартуга каршы кампания тартучылар белән көрәшүгә кайтып калмаска тиеш. Аның төп максаты тәмәке куллануны киметү булсын. Дәүләт Думасы депутаты, Татарстанның атказанган табибы Айрат Фәррахов шундый фикердә. «Тәмәке тартучыларны «мишень»гә алсак, алар качачак. Дәүләткә ышанычларын югалтачак. Без аларга максималь дәрәҗәдә ярдәм итәргә тиеш», – дигән ул.

Депутат әйтүенчә, хәзерге вакытта тәмәкегә каршы алып барылучы сәясәт билгеле бер нәтиҗәләрен күрсәтте. Әмма, аның фикеренчә, тартучылар саны кимеми.

Айрат Фәррахов шулай ук парламентчыларның Түбән палата Рәисе Вячеслав Володин һәм Дума фракцияләре башлыклары белән вейплар өчен сыекчаларны (шул исәптән никотинсыз) тыю турында закон проекты эшләнүен искә төшергән.

Яңалык

Хат ташучы китерәчәк

1 майдан акчалата бирелә торган пенсияне фәкать «Россия почтасы» хезмәткәрләре генә китерәчәк. Федераль закондагы үзгәрешләргә бәйле рәвештә, ил күләмендә шундый яңалык кертелә. Алдан ук искәртеп куйыйк: Татарстанда бу үзгәреш Казан, Түбән Кама шәһәрләрендә, Биектау һәм Лаеш районнарында яшәүче пенсионерларга гына кагылачак.

Яшерен-батырын түгел, безнең халык пенсиягә бәйле бер генә яңалыкка да битараф калмый. Май башыннан керәчәк үзгәреш турында сүз чыккач та, фикерләр икегә бүленде. Берәүләр: «Безгә пенсияне болай да почтальон китерә иде бит инде», – дип аптыраса, икенче берләре пенсиясенең язмышы өчен борчылды. Дөрестән дә, авылларда яшәүче өлкәннәр пенсияне инде күптән почтальон кулыннан ала. Бу яңалык аларга кагылмый, бар да элеккечә калачак.

Закондагы үзгәрешләргә моңа кадәр пенсиясен «Илтеп бирү хезмәте» акционерлык җәмгыяте хезмәткәре китереп биргән өлкәннәргә генә кагыла. Татарстанда мондый хезмәт Казан, Түбән Кама шәһәрләрендә, Биектау һәм Лаеш районнарында яшәүче пенсионерларга күрсәтелгән. Россия Социаль фондының Татарстан Республикасы буенча бүлеге идарәчесе Эдуард Вафин сүзләренә караганда, акчалата пенсияне яңача ала башлау өчен бирегә яшәүче пенсионерларга беркая барырга кирәкми.

Бүген Татарстанда 1,1 миллион пенсионер яши.
Әлегә алар пенсияне өч төрле юл белән ала:
- «Россия почтасы» бүлекләрендә (234,8 мең кеше);
- китереп бирү хезмәте аша (76,2 мең кеше);
- кредит оешмалары аша (805,9 мең кеше).

– Китереп бирү оешмасы сыйфатында «Илтеп бирү хезмәте» акционерлык җәмгыятен сайлаган пенсионерлар, күрсәтелгән көннән башлап, почта элемтәсе бүлекләренә күчерелә. Моның өчен пенсия бүлекләренә килеп, гариза язарга кирәкми. Пенсионерларның шәхси счетларында китереп бирү оешмасын Россия Социаль фонды белгечләре мөстәкыйль рәвештә үзгәртәчәк, – ди ул.

Апрель ае өчен акчалата пенсияне альтернатив хезмәт вәкилләре китерәчәк әле. Май аеннан исә бу хезмәттән файдаланган өлкәннәрнең ишеген почтальон шакыячак. Пенсионерның өйдә чагы булмаса, почтальон аның почта тартмасына язу калдырачак. Пенсионер анда күрсәтелгән номер буенча шалтыратып, почтальон белән пенсия алу көнен кабат килештерә ала. Ул пенсиясен почта бүлекчәсеннән дә барып алырга хокуклы. Үзе өйдә булмаган очракта, пенсионер өчен пенсияне аның якыннары да алып кала ала. Әмма моның өчен аларның кулында ышаныч язуы булырга тиеш.

Ахыры 2 нче биттә >

Сүзгә-сүз

Республика клиник хастаханәсенең баш табибы Рафаэль ШӘВӘЛИЕВ:

«Татар-информ»

Медицина ярдәме күрсәтүдә хирургик активлык күрсәткечен 90 процентка җиткерергә телибез. Бүген ул 78 процент тәшкил итә. РКБ базасында төзеләчәк Трансплантация һәм югары технологияле хирургия үзәге әлеге максатка ирешергә ярдәм итәчәк. Бу 29 мең квадрат метр мәйданлы, җиде катлы заманча корпус булачак дип фаразлана.

(«Татар-информ»га әңгәмәсеннән)

АЗЫК-ТӨЛЕККӘ КҮПМЕ АКЧА КИТӘ?

Росконгресс һәм НАФИ аналитик үзәге оештырган уртак сораштыруда шул сорауга җавап эзләгәннәр.

Россиялеләрнең аена азык-төлек сатып алу чыгымнары >> **6 меңнән 30 мең сумга** кадәр

АЗЫК-ТӨЛЕКНЕ САТЫП АЛАЛАР

80% >> супермаркеттан

49% >> гипермаркеттан

31% >> өйгә якын булган кибетләрдән

Россия Тышкы эшләр министрлыгы мәгълүматлары буенча

Уенчык түгел

Казанда электр самокатлары прокатының дүртенче сезоны ачылды. Аларны шәһәр халкы һәм кунаклар махсус әзерләнгән 500 урында арендага ала алачак. Апрель аенда парковка мәйданын тагын 1100 урынга киңәйтү нияте бар. Шулай итеп самокатларны шәһәр үзәгендә генә түгел, шәһәрнең башка районнарында да файдаланырга мөмкин булачак. Шәһәр халкы һәм кунаклар өчен барлыгы 7,5 меңләп электр самокаты әзерләнгән.

Билгеле булганча, быелның 1 мартыннан юл хәрәкәте кагыйдәләренә кергән төзәтмәләр нигезендә электр самокатлары шәхси мобильлек чарасы булып санала. Әйтик, алардан 14 яше тулмаганнар файдалана алмый. Юлда хәрәкәт итү буенча да катгый таләпләр кертелде. Казанда исә өстәмә кагыйдә бар: самокатның тизлеге сәгатенә 20 чакрымнан артмаска тиеш. 486 урында тизлек чикләнә, тагын 44 урында самокат белән йөрергә бөтенләй ярамый.

ҖИДЕНЧЕ КАТТАН КАРАШ

Наил ШӘРИФУЛЛИН

Глобальләшү дигән туфан

Бу атнада Дәүләт Думасы Кызыл китапка кергән үсемлекләрне өзгән, җыйган өчен җинаять җаваплылыгы керткән закон проектын өченче – соңгы укылышта кабул итте. Аны үтәмәгән очракта 6дан алып 9 елга кадәр иректән мәхрүм ителү куркынычы яный. Шактый кырыс булса да, дөрес, әһәмиятле канун, диясе килә. Табигатьне, андагы күптөрлелекне саклау бик тә кирәк. Тик…

Илдәге милли, мәдәни күптөрлелекне саклау флораны кайгыртудан да мөһимрәк түгел микән? Ул проблема дигәндә, ник катгый кануннар, һич югы норматив документлар шушы көнгәчә юк? Югалып, бетеп барган аз санлы халыклар, кыерсытылган телләрне туплаган Кызыл китап булдыру вакыты җитмәдеме? Бары берничә йөз, хәтта дистә санда гына калган шул ук кырымчак, караим, коряк, дигәндә, ник бүген иң югарыда чаң кагу ишетелми? Хәлнең шактый күңелсезлеген – йөз кешелек халыкларның гына түгел, хәтта миллионлыларның да шактый кызу тизлектә кимеп барганын соңгы җанисәп ачык күрсәтте бит…

Илләр, кыйтгалар буйлап глобальләшү дигән шаукым йөри. Ул туфан булып хәтсез мәдәниятләр, гореф-гадәтләр, телләр өстеннән, аларны таптап, туздырып узарга өлгерде дә инде. Глобальләшү ул – бертөрлелеккә, унификациягә юл тоту. Ул – икътисадый, сәяси һәм мәдәни интеграция. Руслашу, дибез икән, аны да глобальләшү дип атарга мөмкин. Ул – шул шаукымның аерым ил эчендәге кечерәк, җирле варианты. Глобальләшүнең олысы дигәндә, аның икътисадый һәм сәяси ягы – берләшү-интеграция, бер үк стандартлар буенча яшәргә тырышу, ярар, булсын, күзәтелсен дә. Тик менә мәдәни күптөрлелеккә кизәнү… Мәдәниятләр, телләр төрлелеге – кешелекнең бер нәрсә белән дә чагыштырып булмый торган рухи байлыгы, хәзинәсе. Рухи байлыкның, андый мирасның үзенчәлеге – югалгач аны берничек тә кире кайтарып булмый. Нәкъ шуңа да олы дәүләтләрдә яралган, кемдер яхшыга санаган мәдәният, телләр кечеләрне, вакларны йотарга тиеш түгел. Әмма.. Матди байлыклар артыннан күзен тондырып чапкан кешелек мәдәни хәзинәләрнең бәясен белми, затлылыгын күрми. Бу – фаҗига. Ничек инде флора һәм фаунадагы күптөрлелекнең кирәклеген аңлаганда, вак, дәүләт тотмаган халыклар, аларның телләре, гореф-гадәтләре белән исәпләшмәскә мөмкин?

Биредә без янә дә күпмилләтле илләрдәге «дәүләт төзүче» халыкларга, алар эгоизмына килеп төртеләбез. XXI гасыр дәүләте, әгәр дә ул үзен цивилизацияле, алдынгы саный икән, илдә яшәгән бар кавемнәрнең исәнлеге, үсеше, чәчәк атуы турында кайгыртырга тиеш, дип беләм. Кайгырту җәбердән күпкә нәтиҗәлерәк бит. Дәүләт үзе үк: «Ажгырып глобальләшү дигән зәхмәт килә, көчәя, андый шартларда сезгә титульный халыкка караганда күпкә кыенрак. Бирешмәгез! Менә сезгә акча, менә сезгә мөмкинлекләр, менә сезгә кануннар – саклагыз үзегезне», – дияргә тиеш түгелме икән? «Милли мәктәпләрне күбрәк ачыгыз, үз телегездә интернет булдырыгыз, яңа телеканаллар эшләтеп җибәрегез, мәдәниятегезне ныграк пропагандалагыз. Барыннан да бигрәк, телне дәүләт эшендә, рәсми документларда кулланыгыз, парламентларыгызда үз телегездә сөйләшегез – телгә хаҗәт, аны белүгә мотивация тудырыгыз», – дигән сүзләрне кайсы азчылыкларның ишетәсе килми? Һәркем, һәр халык та – Хакның бәндәсе бит.

Үзебез яшәгән ил мисалында, яшерен-батырын түгел, санаган, ишетергә теләгәнебез әлегә хыялда гына кала. Булышучы, хәлебезгә керүче юк, дию генә аз. Кемнәрнеңдер күз алдында һаман да сепаратизм өрәге тырпаеп басып тора: «башка чыга» гына күрмәсеннәр! Илнең тач уртасыннан (Идел-Урал төбәге халыкларын күз алдында тотуым) кая чыгып китеп була соң ул? Кемнәрнеңдер кайчан, кая да булса җыенганы булдымы? Көфер уй ияләренә без алар казанында никадәр тизрәк эретеп бетсәк, шулкадәр яхшы. Вакларны ашлама сыйфатында кулланып, төп халыкны ничек тә ишәйтергә исәпләре. Шунысы да аянычлы: син үзеңнең лояльлегеңне, толерантлыкны исбатлый-исбатлый арып бетсәң дә, дошман яуларына каршы беренче булып йөгерсәң дә, ил казнасына елның-елына йөзәр миллиард сум акча салып торсаң да, хәл үзгәрми.

Ә бит без теләгән мөнәсәбәт, алда саналганнар өлешчә генә үтәлгән, булган очракта без барыбыз да тагын да олырак, кем әйтмешли, мәңге «төзәлмәс» ватанпәрвәр – ил дигәндә минутында, сәгатендә егылып үләргә әзер кешеләр булыр идек. Илдәге эчке сәясәтне билгеләүче кешеләр өчен, күрәмсең, ул кирәкми. Азчылыкларны алар күпме шулай үзләреннән этеп, чит күреп торачак соң?

Глобальләшүнең төп максаты икътисадка, аны булдыра алганча рациональ, азрак чыгымлы итәргә тырышуга барып тоташа. Халыкара хезмәт бүленеше, уртак кырда каршылыксыз йөргән товарлар, хезмәт күрсәтү, акча, шул ук мәгълүмат. Глобальләшү – үскән, камилләшкән капиталистик мөнәсәбәтләр җимеше, ул – мөмкин кадәр күбрәк керем китерүче инструментлар җыелмасы. Мәдәният, телләр буталышы, зурларның кечеләрне кысрыклавы – глобальләшүнең табыш вәгъдә итми торган өстәмә продукты. Һәм, әйтергә кирәк, явыз кимчелеге. Миңа калса, аңа, ул шаукымга каршы тору теләк булганда авыр түгел. Бары табышның кечкенә бер өлешен тел, мәдәниятләрне саклауга юнәлтәсе генә. Әмма ки, бар хикмәт тә шунда: капиталистның өлеш чыгарасы, бүлешәсе килми. Капиталның төп сыйфатларыннан берсе – саранлык. Аның өчен акча мәдәнияттән өстен. Капитализм бу яктан алганда да ләгънәткә лаек. Һәм без аны кызганмый яудырып та торабыз. Ләкин капитал: «Эт өрә, кәрван бара», – дип, проблемалары хәйран күп булса да, яши килә. Кемнәрдер аңа әҗәл юраган тәкъдирдә дә. Юрыйбыз, тик менә капитализмны нәрсә, нинди иҗтимагый-сәяси формация алыштырырга тиеш, ул сорауга җавап бирә алмыйбыз…

Җирдә яралып, озак дәверләр тереклек иткән һәр җан иясенең үз токымын киләчәктә дә яшәтәсе, дәвам иттерәсе килә. Бөҗәкләрдән башлап, имезүче хайваннарга чаклы. Хәтта үсемлекләр дә яшим дип тырыша – асфальт чаклы асфальтны тишеп чыгып үскән, сап-сары булып чәчәк аткан тузганакны берничә тапкыр күргәнем, сокланганым булды. Татарда ташны тишеп чыгарлык пассионарлык 470 ел дәүләтсезлектән соң калгандырмы, әйтү кыен. Шунысы тәгаен: куш глобальләшү шартларында безгә үз тырышлыгыбыз гына җитми. Хәлне аңлаучы, ярдәм итүчеләр кирәк. Кануннар, финанслар, исәнлеккә хәерфатиха бирүчеләр кирәк. Якын араларда булырмы алар?

РӘИС КӨНДӘЛЕГЕ

tatarstan.ru

Татарстан Рәисе РСФСРның һәм ТАССРның халык артистлары Ринат Таҗетдинов белән Равил Шәрәфиевне 85 яшьлек юбилейлары уңаеннан кабул итте, аларга дәүләт бүләкләрен тапшырды.

РӘХМӘТ ИШЕТҮ РӘХӘТ

Кичә «БлагоДарю» социаль адаптация үзәгендә зур кунак булды. Тернәкләнүчеләр янына Татарстан Рәисе Рөстәм Миңнеханов килде.

Башкаланың «БлагоДарю» адаптация үзәге 2019 елдан эшли. Узган ел аның җитәкчесе итеп Гөлнара Галиәхмәтова билгеләнде.

«БлагоДарю»да психик сәламәтлеге какшаган кешеләргә ярдәм итү проекты тормышка ашырыла. Хәзерге көндә әлеге проектта 7 кеше катнаша. Алар – Дәрвишләр бистәсендәге балалар интернат-йортында тәрбияләнүчеләр.

Татарстан Рәисе үзәк эшчәнлеге белән танышты, андагы хезмәткәрләр белән аралашты.

Гөлнара Галиәхмәтова сөйләвенчә, бу проект интеллектуаль яктан мөмкинлекләре чикле кешеләргә яшәү урыны булдыру өчен эшләнгән. Проект «Кадрлар резервы» программасы кысасында Рөстәм Миңнеханов ярдәмен алды.

Үзәктә яшәүче егет-кызлар республика җитәкчесе белән шәхсән аралашты. Алар укый, эшли, гадәти тормышка яраклашкан.

ХӨРМӘТ БИЛГЕСЕ

Аның эшчәнлеге – үсеп килүче буын өчен үрнәк. Татарстан Рәисе ТАССРның 1978–1983 еллардагы эчке эшләр министры, СССРның 1983–1991 еллардагы эчке эшләр министры урынбасары, генерал-лейтенант Николай Демидовка мемориаль такта ачу тантанасында шулай диде.

Истәлек тактасын генерал-лейтенант яшәгән Зур Кызыл урам, 17 нче йортта ачтылар. Тантана аның туган көне алдыннан булды. Исән булса, аңа 90 яшь туласы иде.

– Николай Демидовның хезмәт биографиясенең 20 елы Татарстанга бәйле, – диде Рөстәм Миңнеханов. – Төрле вазыйфаларда эшләгәндә, ул оештыру сәләте, кискен проблемаларны хәл итүдә кешеләрне берләштерү осталыгы белән аерылып торды. Николай Иван улының оештыру таланты эчке эшләр министры вазыйфасында аеруча ачык күренде, ул аны 6 ел дәвамында башкарды. Аның җитәкчелегендә ТАССР Эчке эшләр министрлыгы 1981 елда СССРда иң яхшысы дип танылa. Аның Татарстан һәм бөтен илебез хакына армый-талмый эшләве үсеп килүче буын өчен үрнәк булып тора. Николай Демидов безнең республика халкы, хезмәттәшләре һәм туганнары хәтерендә мәңге калачак.

Искәртеп үтик: Николай Иван улы Демидов 2021 елның 6 октябрендә Мәскәүдә вафат булды. Аңа 88 яшь иде. Николай Демидовны туган ягында – Лаеш районында җирләделәр.

КОТЛЫЙБЫЗ!

Театр сәнгатен үстерүгә мөһим өлеш кертүе һәм күпьеллык нәтиҗәле иҗади эшчәнлеге өчен «Галиәсгар Камал исемендәге Татар дәүләт Академия театры» дәүләт бюджет учреждениесе драма артисты **Шәрәфиев** Равил Шаһап улы **«Дуслык» ордены** белән бүләкләнде.

***

Югары дәрәҗәдәге һөнәри осталыгы, республиканың дәүләт хакимияте органнарында күпьеллык нәтиҗәле хезмәте өчен Татарстан Республикасы Рәисе Эшләр идарәсенең гомуми бүлеге тәрҗемәчеләр төркеме баш белгече **Гарәфетдинова** Гүзәлия Госман кызы **«Татарстан Автономияле Совет Социалистик Республикасы төзелүгә 100 ел» медале** белән бүләкләнде.

***

«Казан (Идел буе) федераль университеты» федераль дәүләт автоном югары белем бирү мәгариф учреждениесенең Халыкара мөнәсәбәтләр институты Тарих фәннәре һәм бөтендөнья мәдәни мирасы югары мәктәбенең антропология һәм этнография кафедрасы профессоры **Титова** Татьяна Алексеевнага **«Татарстан Республикасының атказанган югары мәктәп хезмәткәре»** дигән мактаулы исем бирелде.

Аннан аптырыйбыз

Импортны алыштыру, сәнәгать туризмын үстерү, сәләтле яшьләрне читкә җибәрмәү… Татарстан Дәүләт Советында узган матбугат очрашуында «Татарстан – Яңа Гасыр» депутатлар төркеме җитәкчесе Артур Габделҗанов әнә шул мәсьәләләргә тукталды. Шулай ук башкарган эшләр, киләчәккә планнар турында да сөйләде.

Әлеге депутатлар төркеме патриотик тәрбия, экологик, авыл һәм сәнәгать туризмын үстерү, импортны алыштыру, кайбер социаль проектларны тормышка ашыру өчен җавап бирә. Узган ел «Татарстан – Яңа Гасыр» депутатлар төркеменә халыктан 2680 мөрәҗәгать килгән. Сорауларның күбесе торак-коммуналь, транспорт һәм юл хуҗалыгы мәсьәләләренә кагылган. Депутатлар халык белән районнарда да, шулай ук республика Иҗтимагый кабул итү бүлмәсендә дә очраша. 13–14 апрельдә алар импортны алыштыру мәсьәләләре буенча Алабуга сәнәгать оешмаларында күчмә утырыш уздырырга җыена.

– Татарстанның сәнәгать предприятиеләрендә технологик җиһазлар һәм чимал импортын алыштыруны өйрәнәчәкбез, – диде Артур Габделҗанов.

Аның әйтүенчә, бүген Россия өчен чит илдән кертелә торган товарның күләме кимүе төп һәм катлаулы бурычларның берсе. Барлык өлкәләрдә дә производствоны кирәк-ярак белән тулысынча үзе тәэмин итә алган бер генә ил дә юк. Әлеге проблеманы хәл итү, хәле кискен булган башка төбәкләргә ярдәм итү республиканың көченнән килә.

Бу урында депутат КАМАЗ предприятиесенең авыл хуҗалыгы өчен продукция җитештерү белән генә чикләнмичә, импортны алыштыручы кирәк-ярак җитештерүче заводка әйләнүен әйтте. «Илдә, бигрәк тә республикада автомобильләр җитештерү бик мөһим. Һәм, әлбәттә, бу – безнең җитәкчеләрнең зур хезмәте», – диде депутат.

Артур Габделҗанов сәнәгатьне үстерү өчен, яшьләрне һөнәр сайлауга өйрәтүгә игътибар бирергә, цифрлы профессияләр турында күбрәк сөйләргә кирәк дип саный.

– Без физика, робот техникасы һәм башка илкүләм, республика олимпиадаларында җиңүче егет-кызларны күзәтмибез, барламыйбыз. Аннан, ник алар Татарстаннан читкә китәләр, дип аптырыйбыз. Көнбатыш белгечләре исә аларны үзләренә җәлеп итү җаен таба. 9–10 сыйныфтан ук укучыларга республика үсеше перспективалары, төрле ярдәм чаралары турында сөйли башлау, сәләтле яшьләргә күбрәк игътибар бирү мөһим. Вәгъдә биреп кенә калмыйча, аны үтәргә дә кирәк, – диде Артур Габделҗанов.

Ул шулай ук сәнәгать туризмын үстерүне дә отышлы дип саный. Аның әйтүенчә, Казанга елга 3 миллион турист килә. Моның белән чикләнмичә, башка юнәлешләрне дә ныгытырга, популярлаштырырга кирәк. Сәнәгать туризмы ул – теге яки бу предприятие эшчәнлеге белән кызыксынучы төркемнең төрле оешмаларга экскурсияләргә баруы. Бу юнәлешне үстерү өчен предприятие җитәкчеләренең теләге дә җитә. Яшьләрне производстволарга тарту өчен дә менә дигән мөмкинлек.

Сәрия МИФТАХОВА

Хат ташучы китерәчәк

< Ахыры. Башы 1 нче биттә

«Россия почтасы» ачык акционерлык җәмгыяте Идел макротөбәгенең тышкы коммуникацияләр юнәлеше җитәкчесе Ирина Прохорова сүзләренә караганда, почта хезмәткәрләре пенсияләрне вакытында алып килеп җиткерәчәк.

– Кирәк икән, алар пенсионерга торак-коммуналь хезмәт түләүләрен, салым, ЮХИДИ штрафларын түләргә ярдәм итә, газета-журналларга яздыра ала. Моннан тыш хәзер почтальоннар үзләре белән көндәлек кирәк-ярак товарлары да йөртә. Шул рәвешле кирәк әйберен, өйдән чыкмыйча, алардан гына да алып кала ала. Элек-электән пенсияне почтальон кулыннан алган пенсионерлар бу мөмкинлектән күптән файдалана инде. Почта хезмәткәрләре пенсияләрне вакытында китерәчәк. Түләү көне бәйрәм яки ял көннәренә туры килгән айларда алар пенсияне иртәрәк алып киләчәк, – ди белгеч.

Пенсияне өйгә китереп бирүләре бик уңайлы, билгеле. Шулай да белгечләр уяулыкны югалтмаска өнди. Ник дигәндә, һәр нәрсәдән үзенә файда алып калырга ашыккан мошенниклар бу очракта да активлашырга мөмкин дип кисәтә алар. Бигрәк тә яңалык гамәлгә кергән башлангыч чорда. Моңа кадәр пенсиясен альтернатив хезмәт вәкиле кулыннан алган пенсионер яңа почтальонны йөзгә танып белми бит.

– Шуңа күрә үзен почта хезмәткәре дип таныштырган кешене шундук өйгә кертергә ашыкмагыз. Аның таныклык күрсәтүенә дә ышаныч юк. Мошенниклар ул документны да бик оста үзгәртә. Шикле кеше ишек шакыса, иң элек 8(800)1000000 номеры буенча безгә шалтыратып, сезгә дөрестән дә безнең хезмәткәр килгәнме-юкмы икәнлеген ачыклагыз, – ди Ирина Прохорова.

Динә ГЫЙЛАҖИЕВА

СЫЕРЫМНЫҢ ТУГАН КӨНЕ

Авыл хәлләре

Шушы көннәрдә генә авылда тагын ветеринарлар йөрде. Тагын дим, әле бер айлап элек кенә сыер малларын чиплап – колакларына номерлар тагып киткәннәр иде. Бу юлы эре малларга себер түләмәсенә каршы прививка ясасалар, этләргә котыру чиренә каршы укол кададылар.

Илдар Мөхәммәтҗанов

Бер елга һәр хуҗалыкка ничә тапкыр керәләрдер, алар үзләре нәрсәгә прививка ясауларын әйтсәләр дә, чын, бөтенесен истә тотып бетерә торган түгел. Алан ветучасток табибларын без дә таныйбыз, алар да безне белә.

– Бөтен авыл этләрен котыртып йөрибез әле, – дип керде бу юлы табиблар. Дөрестән дә, тирә-күршедәге бөтен эт өрә. Алар инде ветеринарларның исен болай да әллә каян белә, өстәвенә бу юлы үзләрен авырттырганнар. Моннан дистә еллап элек этләргә беренче тапкыр укол кадатканда гына сәер булган иде, ул чакта әле этләрне сыерлардан кан ала торган махсус урынга – авылның икенче очына алып төшәсе булды. Гомеренә урам күрмәгән этне авыл буйлап йөртеп кайту үзе бер маҗара булган иде. Шөкер, аннан соңгы елларда монысын да өй борынча йөреп эшли башладылар. Этләргә укол кадау сыер малына караганда да кыенрак. «Бигрәк тә кечкенә этләр куркыныч, хуҗалары кулыннан шуып чыгып китәләр», – ди табиблар үзләре.

Борынчык киертми генә, оясы түбәсенә ике аягын күтәртеп бастырып, авызын бер кул белән тотып торган хатын-кызга бик ышанып бетәселәре килми дә үзе. Ә эт белән безнең дуслык көчле, миңа ышанып, тыныч кына тора, «эһ» тә итми ул, мескен. Табиблар читкә китеп, мин кулларны җибәргәч кенә характер күрсәтеп ала.

Ярый әле хәзер сыерларга укол-прививкаларны «автомат» шприцлар белән генә кадыйлар дип сөенәм мин. Укол кадаганны да, кан алганны да белми дә калалар. Соңгысы да уңайлы, канны хәзер койрык төбеннән генә алалар. Элек мал иясенә сыерның башын каерып тотарга, табибка венага туры китереп, энә кадарга кирәк иде. Мал тик тормый, шул сәбәпле энә венадан чыгып китә, тагын көч белән сугып кертәсе. Шуңа күрә хәзер укол кадатканда да, кан алдырганда да көчле беләкле кеше булу кирәк түгел, малның кайдалыгын күрсәтеп, бераз тынычландырып торучы булса, җитә.

– Шушы арада субсидия алу өчен килешү төзергә барасыгыз була, – диде безгә кергән мал табибы, уколларын кадап бетергәннән соң. – Сыерыгызның колагындагы номерын язып алып барыгыз. Хәзер инде Машка-Дашкалар бетте, сыерыгыз 74908 булып йөри…

Сыерыбыз болай да Машка–Дашка түгел иде, гомергә саф татарча Ландыш булды. Кировтан кайткан Рыбканы да бер җәйдә Ландышка әйләндердек. Хикмәт исемдә түгел, болай да аптырый торган иде инде, иминиятләштерә башласаң да, субсидия алырга документлар тутырсаң да, сыерның кушаматын сорыйлар. Табибның шуңа әйтүе. Белмим, кушаматлары бу документларда нинди роль уйныйдыр, аңа карап, субсидия барыбер безнең исемгә килә… Менә кушаматлар заманы да үтте, димәк. Хәер, гел яңалык кертеп торганнарына аптырамыйбыз да бугай инде: ул сыер маллары белән нинди генә тәҗрибә үткәрмәделәр. Бер елны хәзер бөтен җиргә шушы документ белән генә киләчәксез дип, малларга ветеринария паспорты эшләткәннәр иде. Бер тапкыр да сораучы булмады, кирәге дә чыкмады. Белмим, фәләнчә битле ул брошюраларны эшләтү кем идеясе булган да кемгә табыш китергәндер?

Быелгы тагын бер яңалык: чиплаган вакытта сыерның… туган көнен дә сорадылар. Ярый әле этисенең исемен, туган авылын, урынын сорамадылар. Киров өлкәсенә барып эзләп йөрергә туры килмәде, дип сөенсәң генә. Ул инде сыерның яшен, ничәне бозаулаганын барган бер җирдә сөйли-сөйли үзебез дә буташып бетә торган. Мин сыерның туган көне кайчан дигән сораудан аңга килә алмый басып торганда, уен-көлкеле табиб: «Әйдә, мәңге онытылмый торган числоны язийк: 26 апрель булсын», – диде. Шулай итеп авылда 26 апрельдә туган сыерлар шактыйга җыелгандыр…

Әйткәнемчә, моннан берничә ел элек иминиятләштергәндә сыерларны фотога төшерә башладык: алдан да, ике як-яннан да… Бер танышыма теге чакта – сыерны беренче тапкыр фотога төшергәндә аптырап әйткән идем, озакламый тояк эзләрен дә алмасалар ярый инде, дип куйды. Эшләр шуңа бара, ахры…

Гөлсинә ХӘБИБУЛЛИНА

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ЗАКОННАРЫ

Татарстан Республикасының аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында

Татарстан Республикасы Дәүләт Советы тарафыннан 2023 елның 23 мартында кабул ителде

1 статья

«Татарстан Республикасының бәйрәм көннәре һәм истәлекле даталары турында» 1992 елның 19 февралендәге 1448-XII номерлы Татарстан Республикасы Законына (2010 елның 14 октябрендәге 74-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы редакциясендә) (Татарстан Югары Советы Җыелма басмасы, 1992, № 4; Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 2010, № 10 (II өлеш); Татарстан Республикасы законнар җыелмасы, 2016, № 25 (I өлеш) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1) 1 статьяның 4 өлешендә «Татарстан Республикасы Президенты» сүзләрен «Татарстан Республикасы Рәисе» сүзләренә алмаштырырга;

2) 2 статьяда:

а) 1 өлештә «Татарстан Республикасы Президенты» сүзләрен «Татарстан Республикасы Рәисе» сүзләренә алмаштырырга;

б) 2 өлештә «Татарстан Республикасы Президенты» сүзләрен «Татарстан Республикасы Рәисе» сүзләренә алмаштырырга.

2 статья

«Татарстан Республикасы дәүләт телләре һәм Татарстан Республикасында башка телләр турында» 1992 елның 8 июлендәге 1560-XII номерлы Татарстан Республикасы Законына (2004 елның 28 июлендәге 44-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы редакциясендә) (Татарстан Югары Советы Җыелма басмасы, 1992, № 6; Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 2004, № 7 (I өлеш); 2009, № 12 (I өлеш); 2012, № 3; 2014, № 6 (II өлеш); Татарстан Республикасы законнар җыелмасы, 2017, № 33 (I өлеш); 2022, № 83 (I өлеш) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1) 10 статьяда:

а) исемендә «Татарстан Республикасы Президенты Аппаратының» сүзләрен «Татарстан Республикасы Рәисе Администрациясенең» сүзләренә алмаштырырга;

б) беренче өлештә «Татарстан Республикасы Президенты Аппаратында» сүзләрен «Татарстан Республикасы Рәисе Администрациясендә» сүзләренә алмаштырырга;

2) 11 статьяда «Татарстан Республикасы Президенты» сүзләрен «Татарстан Республикасы Рәисе» сүзләренә алмаштырырга.

3 статья

«Татарстан Республикасында яшьләр сәясәте турында» 1993 елның 19 октябрендәге 1983-XII номерлы Татарстан Республикасы Законының 13 статьясындагы 3 өлешенә (2021 елның 5 маендагы 35-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы редакциясендә) (Татарстан Югары Советы Җыелма басмасы, 1993, № 10; Татарстан Республикасы законнар җыелмасы, 2021, № 36 (I өлеш); 2023, № 11 (I өлеш), «Татарстан Республикасы Президентына» сүзләрен «Татарстан Республикасы Рәисенә» сүзләренә алмаштырып, үзгәреш кертергә.

4 статья

«Фән һәм фәнни эшчәнлек турында» 1998 елның 18 июнендәге 1661 номерлы Татарстан Республикасы Законының 7 статьясындагы 5 пунктына (Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 1998, № 7; 2006, № 5; 2014, № 6 (II өлеш); Татарстан Республикасы законнар җыелмасы, 2016, № 3 (I өлеш); 2020, № 87 (I өлеш); 2022, № 49 (I өлеш), «Татарстан Республикасы Президентына» сүзләрен «Татарстан Республикасы Рәисенә» сүзләренә алмаштырып, үзгәреш кертергә.

5 статья

«Мәдәният турында» 1998 елның 3 июлендәге 1705 номерлы Татарстан Республикасы Законының 18^1 статьясындагы унынчы өлешенә (Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 1998, № 7; 2000, № 12 (11) (II өлеш); 2006, № 12 (I өлеш); 2007, № 11; 2009, № 7 – 8 (I өлеш); 2011, № 3; 2012, № 3; 2013, № 12 (I өлеш); 2014, № 6 (II өлеш); 2015, № 3, № 12 (I өлеш); Татарстан Республикасы законнар җыелмасы, 2018, № 1 (I өлеш), № 54 (I өлеш), № 83 (I өлеш); 2019, № 40 (I өлеш); 2021, № 36 (I өлеш), «Татарстан Республикасы Президентының» сүзләрен «Татарстан Республикасы Рәисенең» сүзләренә алмаштырып, үзгәреш кертергә.

6 статья

Татарстан Республикасы Җир кодексының 33^3 статьясына (2005 елның 18 гыйнварындагы 4-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы редакциясендә) (Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 1998, № 8 (II өлеш); 2005, № 1 (I өлеш), № 12 (I өлеш); 2006, № 7 (I өлеш); 2007, № 1 (I өлеш), № 4; 2008, № 5 (I өлеш); 2009, № 7 – 8 (III өлеш); 2010, № 11; 2011, № 11 (I өлеш); 2012, № 3, № 5 (I өлеш); 2013, № 1; 2014, № 3, № 5, № 6 (II өлеш), № 7, № 12 (II өлеш); 2015, № 7 (I өлеш), № 10 (I өлеш); 2016, № 5; Татарстан Республикасы законнар җыелмасы, 2016, № 40 (I өлеш); 2017, № 41 (I өлеш), № 52 (I өлеш), № 76 (I өлеш); 2018, № 1 (I өлеш), № 22 (I өлеш), № 78 (I өлеш); 2019, № 2 (I өлеш), № 60 (I өлеш); 2020, № 77 (I өлеш); 2021, № 1 (I өлеш), № 20 (I өлеш), № 29 (I өлеш), № 57 (I өлеш), № 77 (I өлеш), № 93 (I өлеш); 2022, № 3 (I өлеш), № 17 (I өлеш), № 57 (I өлеш), № 77 (I өлеш), № 83 (I өлеш); 2023, № 11 (I өлеш) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1) 1 пунктта «Татарстан Республикасы Президенты» сүзләрен «Татарстан Республикасы Рәисе» сүзләренә алмаштырырга;

2) 4 пунктта «Татарстан Республикасы Президентына» сүзләрен «Татарстан Республикасы Рәисенә» сүзләренә алмаштырырга;

3) 5 пунктта «Татарстан Республикасы Президенты» сүзләрен «Татарстан Республикасы Рәисе» сүзләренә алмаштырырга.

7 статья

«Татарстан Республикасының дәүләт символлары турында» 1999 елның 14 июлендәге 2284 номерлы Татарстан Республикасы Законына (Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 1999, № 8 (I өлеш); 2003, № 8; 2006, № 2 (I өлеш), № 11 (I өлеш); 2013, № 3; 2016, № 4; Татарстан Республикасы законнар җыелмасы, 2022, № 83 (I өлеш) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1) 2 статьяда:

а) беренче өлештә:

1 пунктта «Татарстан Республикасы Президенты» сүзләрен «Татарстан Республикасы Рәисе» сүзләренә алмаштырырга;

2 пунктның беренче абзацында «Татарстан Республикасы Президентының» сүзләрен «Татарстан Республикасы Рәисенең» сүзләренә алмаштырырга;

3 пунктта «Татарстан Республикасы Президенты» сүзләрен «Татарстан Республикасы Рәисе» сүзләренә алмаштырырга, «Татарстан Республикасы Президенты, Татарстан Республикасы Дәүләт Советы, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты Аппаратлары, Татарстан Республикасы Үзәк сайлау комиссиясе, Татарстан Республикасы даими комиссияләре» сүзләрен «Татарстан Республикасы Рәисе Администрациясе, Татарстан Республикасы Дәүләт Советы, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты, Татарстан Республикасы Үзәк сайлау комиссиясе, Татарстан Республикасы даими вәкиллекләре аппаратлары» сүзләренә алмаштырырга;

4 пунктта «Татарстан Республикасы Президентының» сүзләрен «Татарстан Республикасы Рәисенең» сүзләренә алмаштырырга;

б) өченче өлештә «Татарстан Республикасы Президенты» сүзләрен «Татарстан Республикасы Рәисе» сүзләренә алмаштырырга;

2) 9 статьяның беренче өлешендәге 2 пунктында «Татарстан Республикасы Президенты» сүзләрен «Татарстан Республикасы Рәисе» сүзләренә алмаштырырга;

3) 10 статьяда:

а) беренче өлештә «Татарстан Республикасы Президентының» сүзләрен «Татарстан Республикасы Рәисенең» сүзләренә алмаштырырга;

б) икенче өлештә «Татарстан Республикасы Президентының» сүзләрен «Татарстан Республикасы Рәисенең» сүзләренә алмаштырырга;

в) өченче өлештә «Татарстан Республикасы Президенты» сүзләрен «Татарстан Республикасы Рәисе» сүзләренә алмаштырырга;

4) 19 статьяның өченче абзацында «Татарстан Республикасы Президенты» сүзләрен «Татарстан Республикасы Рәисе» сүзләренә алмаштырырга;

5) 20 статьяда «Татарстан Республикасы Президенты» сүзләрен «Татарстан Республикасы Рәисе» сүзләренә алмаштырырга.

8 статья

«Татарстан Республикасының Законнар җыентыгы турында» 1999 елның 15 сентябрендәге 2355 номерлы Татарстан Республикасы Законының 1 статьясындагы икенче өлешенең алтынчы абзацына (Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 1999, № 10; 2004, № 3 (II өлеш); 2009, № 2; Татарстан Республикасы законнар җыелмасы, 2018, № 92 (I өлеш), «Татарстан Республикасы Президентының» сүзләрен «Татарстан Республикасы Рәисенең» сүзләренә алмаштырып, үзгәреш кертергә.

9 статья

«Татарстан Республикасында Кеше хокуклары буенча вәкаләтле вәкил турында» 2000 елның 3 мартындагы 95 номерлы Татарстан Республикасы Законына (Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 2000, № 3 (3); 2003, № 8; 2008, № 11 (III өлеш); 2010, № 6 (I өлеш); 2011, № 8 (I өлеш); 2013, № 2 (I өлеш); 2014, № 6 (II өлеш); 2015, № 6 (II өлеш); Татарстан Республикасы законнар җыелмасы, 2017, № 41 (I өлеш); 2020, № 51 (I өлеш); 2021, № 1 (I өлеш), № 57 (I өлеш); 2022, № 49 (I өлеш), № 83 (I өлеш) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1) II бүлекнең исемендә «сайлап кую» сүзләрен «билгеләп кую» сүзләренә алмаштырырга;

2) 4 статьяда:

а) исемендә «сайлап кую» сүзләрен «билгеләп кую» сүзләренә алмаштырырга;

б) «сайлап куела» сүзләрен «билгеләп куела» сүзләренә алмаштырырга;

3) 5 статьяда «Татарстан Республикасы Президенты» сүзләрен «Татарстан Республикасы Рәисе» сүзләренә алмаштырырга;

4) 6 статьяның 1 өлешендә «сайлап куела» сүзләрен «билгеләп куела» сүзләренә алмаштырырга;

5) 7 статьяның 2 өлешендә «сайланганнан» сүзен «билгеләп куелганнан» сүзләренә алмаштырырга;

6) 8 статьяда:

а) 1 өлештә «сайлана» сүзен «билгеләп куела» сүзләренә алмаштырырга;

б) 2 өлештә «сайланган» сүзен «билгеләп куелган» сүзләренә алмаштырырга;

в) 2^1 өлештә «сайлап куела» сүзләрен «билгеләп куела» сүзләренә алмаштырырга;

7) 12 статьяда:

а) 1 өлештә «сайланган» сүзен «билгеләп куелган» сүзләренә алмаштырырга;

б) 5 өлештә «сайлап куелырга» сүзләрен «билгеләп куелырга» сүзләренә алмаштырырга;

8) 26 статьяда «Татарстан Республикасы Президентына» сүзләрен «Татарстан Республикасы Рәисенә» сүзләренә алмаштырырга;

9) 27 статьяның 1 өлешендә «Татарстан Республикасы Президентына» сүзләрен «Татарстан Республикасы Рәисенә» сүзләренә алмаштырырга.

10 статья

«Хуҗалык җәмгыятьләренең һәм ширкәтләренең идарә итү һәм тикшереп тору органнарында дәүләт вәкилләренең катнашу тәртибе турында» 2000 елның 19 октябрендәге 383 номерлы Татарстан Республикасы Законына (Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 2000, № 11 (9); 2005, № 12 (I өлеш); 2015, № 10 (I өлеш) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1) 2 статьяда:

а) беренче өлешнең «а» пунктчасында «Татарстан Республикасы Президенты» сүзләрен «Татарстан Республикасы Рәисе» сүзләренә алмаштырырга, «Татарстан Республикасы Президенты Аппаратында» сүзләрен «Татарстан Республикасы Рәисе Администрациясендә» сүзләренә алмаштырырга;

б) бишенче өлештә «Татарстан Республикасы Президенты» сүзләрен «Татарстан Республикасы Рәисе» сүзләренә алмаштырырга;

2) 4 статьяда:

а) беренче өлештә «Татарстан Республикасы Президенты» сүзләрен «Татарстан Республикасы Рәисе» сүзләренә алмаштырырга;

б) икенче өлештә «Татарстан Республикасы Президенты» сүзләрен «Татарстан Республикасы Рәисе» сүзләренә алмаштырырга;

в) дүртенче өлештә «Татарстан Республикасы Президенты» сүзләрен «Татарстан Республикасы Рәисе» сүзләренә алмаштырырга;

3) 5 статьяның беренче өлешендә «Татарстан Республикасы Президенты» сүзләрен «Татарстан Республикасы Рәисе» сүзләренә алмаштырырга.

11 статья

«Татарстан Республикасы судьяларының квалификация коллегиясендә җәмәгатьчелек вәкилләре турында» 2002 елның 15 октябрендәге 14-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законына (Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 2002, № 10; 2003, № 9 (II өлеш); 2013, № 4 (I өлеш); 2015, № 10 (I өлеш); Татарстан Республикасы законнар җыелмасы, 2021, № 20 (I өлеш) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1) 3 статьяда:

а) 1 өлештә «Татарстан Республикасы Президенты» сүзләрен «Татарстан Республикасы Рәисе» сүзләренә алмаштырырга;

б) 3 өлештә «Татарстан Республикасы Президенты» сүзләрен «Татарстан Республикасы Рәисе» сүзләренә алмаштырырга;

в) 4 өлештә «Татарстан Республикасы Президенты» сүзләрен «Татарстан Республикасы Рәисе» сүзләренә алмаштырырга;

2) 4 статьяда:

а) 2 өлештә «Татарстан Республикасы Президенты» сүзләрен «Татарстан Республикасы Рәисе» сүзләренә алмаштырырга;

б) 3 өлештә «Татарстан Республикасы Президентына» сүзләрен «Татарстан Республикасы Рәисенә» сүзләренә алмаштырырга.

12 статья

«Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәте турында» 2003 елның 16 гыйнварындагы 3-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законына (2005 елның 25 октябрендәге 106-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы редакциясендә) (Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 2003, № 1; 2005, № 10 (II өлеш); 2006, № 12 (I өлеш); 2007, № 11; 2008, № 3, № 10 (I өлеш), № 12 (I өлеш); 2009, № 12 (I өлеш); 2010, № 1 – 2, № 10 (II өлеш); 2011, № 5, № 11 (I өлеш); 2012, № 7 (I өлеш); 2013, № 2 (I өлеш), № 3, № 11 (I өлеш); 2014, № 5, № 6 (II өлеш), № 7, № 12 (II өлеш); 2015, № 7 (I өлеш); 2016, № 4, № 7 – 8, № 9 (II өлеш); Татарстан Республикасы законнар җыелмасы, 2017, № 1 (I өлеш), № 85 (I өлеш); 2018, № 1 (I өлеш), № 29 (I өлеш), № 54 (I өлеш), № 78 (I өлеш); 2020, № 4 (I өлеш), № 37 (I өлеш), № 87 (I өлеш); 2021, № 1 (I өлеш), № 57 (I өлеш); 2022, № 34 (I өлеш), № 96 (I өлеш) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1) 7 статьяда:

а) 1 өлешнең 2 пунктында «Татарстан Республикасы Президенты» сүзләрен «Татарстан Республикасы Рәисе» сүзләренә алмаштырырга;

б) 2 өлештә «Татарстан Республикасы Президенты» сүзләрен «Татарстан Республикасы Рәисе» сүзләренә алмаштырырга;

2) 9 статьяның 2 өлешендә «Татарстан Республикасы Президенты» сүзләрен «Татарстан Республикасы Рәисе» сүзләренә алмаштырырга;

3) 11^2 статьяда:

а) 7 өлештә:

беренче абзацта «Татарстан Республикасы Президенты» сүзләрен «Татарстан Республикасы Рәисе» сүзләренә алмаштырырга;

1 пунктта «Татарстан Республикасы Президенты Аппараты» сүзләрен «Татарстан Республикасы Рәисе Администрациясе» сүзләренә алмаштырырга;

б) 8 өлешнең 1 пунктында «Татарстан Республикасы Президенты Аппаратында» сүзләрен «Татарстан Республикасы Рәисе Администрациясендә» сүзләренә алмаштырырга, «Татарстан Республикасы Президенты Аппараты» сүзләрен «Татарстан Республикасы Рәисе Администрациясе» сүзләренә алмаштырырга, «Татарстан Республикасы Президенты» сүзләрен «Татарстан Республикасы Рәисе» сүзләренә алмаштырырга;

в) 11 өлештә «Татарстан Республикасы Президенты» сүзләрен «Татарстан Республикасы Рәисе» сүзләренә алмаштырырга;

4) 13 статьяның 6 өлешендә «Татарстан Республикасы Президенты» сүзләрен «Татарстан Республикасы Рәисе» сүзләренә алмаштырырга;

5) 17 статьяда:

Татарстан Республикасының дәүләт милке яисә муниципаль милек булып торган балалар өчен социаль инфраструктура объектын реконструкцияләү, модернизацияләү, аның билгеләнешен үзгәртү яисә аны бетерү турында йә балалар өчен социаль инфраструктура булдыручы Татарстан Республикасы дәүләт оешмаларын яисә муниципаль оешмаларны үзгәртеп төзү яисә бетерү турында карар кабул итү нәтиҗәләрен бәяләүне үткәрү тәртибе, мондый карар кабул итү нәтиҗәләрен бәяләү комиссиясен төзү һәм әлеге комиссия тарафыннан бәяләмәләр әзерләү тәртибе, әлеге өлешнең бишенче абзацы нигезендә билгеләнгән гомуми принципларны исәпкә алып, тиешенчә Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты, җирле үзидарә органнары тарафыннан билгеләнә.»;

б) 3 өлештә:

беренче абзацта «Татарстан Республикасының дәүләт милке» сүзләреннән соң «яисә муниципаль милек» сүзләрен өстәргә, түбәндәге эчтәлекле җөмлә өстәргә: «Балаларның ялын оештыру һәм аларны савыктыру өчен билгеләнгән объектларны урнаштыру өчен бирелгән җир кишәрлекләренең максатчан билгеләнешен һәм (яисә) алардан рөхсәт ителгән файдалану төрен үзгәртү, Федераль законның 13 статьясындагы 2 пункты нигезендә дәүләт милке яисә муниципаль милек булып торган балалар өчен социаль инфраструктура объектының билгеләнешен үзгәртү яисә аны бетерү рөхсәт ителә торган очраклардан һәм мондый җир кишәрлекләрен дәүләт ихтыяҗлары яисә муниципаль ихтыяҗлар өчен тартып алу очракларыннан тыш, тыела.»;

икенче абзацта түбәндәге эчтәлекле җөмлә өстәргә: «Муниципаль милек булып торган һәм балаларга белем бирү, аларны үстерү, аларның ялы һәм аларны савыктыру, балаларга медицина ярдәме күрсәтү һәм алардагы авыруларны профилактикалау, балаларны социаль яклау һәм аларга социаль хезмәт күрсәтү максатлары өчен билгеләнгән мөлкәт муниципаль хокукый актларда билгеләнгән тәртиптә кулланыла.».

2 статья

Әлеге Закон рәсми басылып чыккан көненнән соң 10 көн узгач үз көченә керә.

Татарстан Республикасы Рәисе Р.Н. Миңнеханов

Казан, Кремль
2023 ел, 06 апрель
№ 32-ТРЗ

Татарстан Республикасы Экология кодексына һәм «Татарстан Республикасының азык-төлек куркынычсызлыгы турында» Татарстан Республикасы Законының 6 һәм 9 статьяларына үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы Дәүләт Советы тарафыннан 2023 елның 23 мартында кабул ителде

1 статья

Татарстан Республикасы Экология кодексына (Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 2009, № 1; 2010, № 5 (I өлеш); 2011, № 6 (I өлеш), № 10 (I өлеш); 2012, № 1; 2013, № 1; 2014, № 5, № 6 (II өлеш), № 7; 2015, № 4; 2016, № 1 – 2, № 5; Татарстан Республикасы законнар җыелмасы, 2016, № 40 (I өлеш), № 44 (I өлеш); 2017, № 27 (I өлеш); 2018, № 54 (I өлеш); 2019, № 2 (I өлеш), № 19 (I өлеш); 2020, № 4 (I өлеш), № 37 (I өлеш), № 57 (I өлеш), № 77 (I өлеш); 2021, № 20 (I өлеш), № 57 (I өлеш), № 93 (I өлеш); 2022, № 34 (I өлеш), № 57 (I өлеш), № 83 (I өлеш) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1) 5 статьяда:

а) 1 өлештә «, шулай ук Россия Федерациясе дәүләт хакимияте органнары һәм Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте органнары арасында эшләр һәм вәкаләтләр бүлешү турында шартнамә» сүзләрен төшереп калдырырга;

б) 2 өлештә «, шулай ук Россия Федерациясе дәүләт хакимияте органнары һәм Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте органнары арасында эшләр һәм вәкаләтләр бүлешү турында шартнамә» сүзләрен төшереп калдырырга;

2) 6 статьяның бишенче абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Россия Федерациясе законнары һәм Татарстан Республикасы законнары нигезендә башка вәкаләтләр.»;

3) 7 статьяда:

а) исемендә «Татарстан Республикасы Президенты» сүзләрен «Татарстан Республикасы Рәисе» сүзләренә алмаштырырга;

б) беренче абзацта «Татарстан Республикасы Президенты» сүзләрен «Татарстан Республикасы Рәисе» сүзләренә алмаштырырга;

в) җиденче абзацны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Россия Федерациясе законнары һәм Татарстан Республикасы законнары нигезендә башка вәкаләтләр.»;

4) 8 статьяның 1 өлешендәге кырыгынчы абзацны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Россия Федерациясе законнары һәм Татарстан Республикасы законнары нигезендә башка вәкаләтләр.»;

5) 13 статьяның 3 өлешендә «Татарстан Республикасы Президенты» сүзләрен «Татарстан Республикасы Рәисе» сүзләренә алмаштырырга.

2 статья

«Татарстан Республикасының азык-төлек куркынычсызлыгы турында» 2017 елның 13 июлендәге 53-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законына (Татарстан Республикасы законнар җыелмасы, 2017, № 52 (I өлеш) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1) 6 статьяда:

а) исемендә «Татарстан Республикасы Президенты» сүзләрен «Татарстан Республикасы Рәисе» сүзләренә алмаштырырга;

б) беренче абзацны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Татарстан Республикасы Рәисе:»;

в) 3 пунктта «җирле үзидарә органнары» сүзләреннән соң «, Россия Федерациясендә гавами хакимиятнең бердәм системасына керә торган башка органнары» сүзләрен өстәргә;

2) 9 статьяның 1 пунктында «җирле үзидарә органнары» сүзләреннән соң «, Россия Федерациясендә гавами хакимиятнең бердәм системасына керә торган башка органнары» сүзләрен өстәргә.

3 статья

Әлеге Закон рәсми басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

Татарстан Республикасы Рәисе Р.Н. Миңнеханов

Казан, Кремль
2023 ел, 06 апрель
№ 33-ТРЗ

«...ИЛГӘ КАЙГЫ КИЛМӘСЕН»

Бу җырны кем, кайчан, нәрсә уңаеннан чыгарганын белеп булмый, әмма без аны гомер бакый җырлыйбыз кебек. Җырламас идек, ул һәркемнең язмышы белән бәйләнгән. Илгә берәр кайгы килдеме, без аны уртак дип кабул итәргә өйрәнгән. «Ялгыз кайгы – кайгымыни, илгә кайгы килмәсен...» – дип җыр сузуыбыз – шуңа бер дәлил. Төптәнрәк уйлап карасаң, Ватанны ярату хисләрен татар әнә шулай көйгә салып, гади генә итеп әйткән дә биргән.

Булат үзенең улы Камил, хатыны Руфия һәм әнисе Сәрия белән.

Без Украинада барган махсус хәрби операцияне дә уртак кайгы дип кабул иттек. Халык аны «операция» түгел, «сугыш» дип сөйли. Бу – чыннан да сугыш, фашизмга каршы сугыш. Минем белән риза булмаучылар да табылыр. Нинди дә булса милләт турында, ул халык яшәргә тиеш түгел, аны тамырыннан корытырга, телсез, хәтта динсез калдырырга кирәк, диючеләрне «фашист» димичә, кем дисең? Фашизм – 1920 нче елларда Италиядә барлыкка килгән режим. Фашистик идеология дәүләтне иң югары кыйммәт дип саный, ә халык – бу идеология өчен оештырылган бер төркем генә. Фашизм белән нацизм – «ике чабата бер кием» дияргә була, тегесе дә, бусы да аерым бер милләтнең башкалардан аерылып торуына, төрле расаларның, милләтләрнең үзара сугышып яшәвенә нигезләнә. Тарих моны гел раслый килә.

Күптән түгел Арчага кайткан идем, район башлыгы Илшат Нуриев янына да кереп чыктым. Хәзер бит ни турында гына сүз башласаң да, «тел Киевка илтә», без дә Украинадагы хәлләр турында сөйләшеп утырдык. Махсус хәрби операциядә Арчадан 300гә якын егет катнаша икән, мин мобилизацияләнгәннәрне күз алдында тотам. Илшат Габделфәрт улының шулар янына барып кайтканын ишеткән идем инде, гуманитар ярдәм илтергә ни өчен район башлыгы үзе барды икән, дип бераз гаҗәпләнеп тә куйдым. Ә ул: «Татар тотып карамыйча ышанмый бит, якташларның нинди шартларда хезмәт итүләрен үз күзем белән күреп кайтасым килде. Шөкер, ашау-эчүләре әйбәт, күзләре янып тора», – диде.

Арча егетләре алгы сызыкта да, резервта да икән. Окопларны, блиндажларны, казармаларны да карап чыккан район башлыгы. Иң кирәкле бөтен нәрсә бар. Әмма Арчадан алып килгән өй ризыгында, һәр күчтәнәчтә әти-әниләренең, туганнарының, дус-ишләренең күңел җылысы була бит ул. Егетләр моны тоя: «Беразга гына булса да туган якларга кайтып килдек», – дип куанышалар икән. Аларга әле «исемле күчтәнәч»ләр дә алып килгәннәр. Һәм: «Күчтәнәчләрдән бушаган банка, савыт-сабаны үзләре кире кайтарсыннар», – дип әйтеп тә җибәргәннәр. «Исән-сау әйләнеп кайтыгыз!» – дигән сүзләрне менә шулай үзләренчә әйтә якташларым. Арча егете, Дәүләт Советы депутаты Лотфулла Шәфигуллин ике «УАЗ» машинасы җибәргән. Бәлки, ул да егетләр шул машиналарга утырып кире кайтырлар дип уйлагандыр. Инде Арчадан 20ләп зур машина да җибәрелүен әйтсәк, кире кайтырга һәркемгә урын җитә дигән сүз. Әле егетләребез өчен җыелма мунчалар да алып барганнар. Арча бүрәнәләреннән буралган мунча җылысы да туган як җылысы кебек тоелмый калмас дип уйлыйк.

Илшат Габделфәрт улы полк командиры белән сөйләшеп (ул да Арча егете икән, позывное – «Алтай»), егетләрнең әниләрен, хатыннарын, апа-сеңелләрен 8 Март белән котлауларын видеога төшерттергән. Кайткач, җыелышып, елмаешып-елашып дигәндәй, бергә караганнар.

Мин Украинадагы хәлләрне телевизордан күзәтеп барам. Кайбер вакыйгалар кеше ышанмаслык кебек тоела. Әмма, Илшат Нуриевны тыңлагач, күңелдә бер генә шик тә калмый. Украинада чын мәгънәсендә фашистик режим урнашкан икән. Заманында Балтачта колхоз рәисе булып эшләгән Зиннур Зәйнуллин белән сөйләшеп торган район башлыгы. Зиннур абыйның бертуган апасы гаиләсе белән ДНРда яши икән. Сигез ел эчендә ничек иза чиккәннәрен энесенә елый-елый сөйләгән ул. «Балалар йокыдан торганчы бөтен җирне карап-тикшереп чыга идек. Чөнки Украина милләтчеләре кем украин түгел, шуларның ишегалларына, бәрәңге араларына, җимеш куаклары төпләренә, ишек-капкаларга гранаталар (растяжкалар) куялар иде. Көн саен кайдадыр шартлый, кемдер үлә. Бу хәлләргә ничек чыдамак кирәк», – дип сөйләгән ул. Демократик дәүләт төзергә омтылган Украинада алып барылган бүгенге сәясәтнең асылын берничә сүз белән «украин булмаган милләтләрнең яшәргә хакы юк» дип әйтеп биреп булыр иде. Бүгенге режим өчен башка милләт вәкиле кеше түгел булып чыга.

Арчага кайткач, район газетасы редакциясенә керми калганым юк. Каләмдәшләрем кайда нәрсә «шылт» иткәнен белеп тора. «Арча хәбәрләре» газетасы махсус хәрби операция турында атна саен тулы бер бит чыгарып бара икән. Авыр, четерекле тема бу, теләсә кем язарга алынмас. Әмма язарга кирәк. Бу эшне Гөлсинә Зәкиевага тапшырганнар. «Кайвакыт үземнең елыйсылар килә, ярты картаям инде», – дип елмайгандай итә Гөлсинә. Мин: «Хатын-кыз – көчле зат ул», – дип салпы якка салам кыстырган булам. Гөлсинә миңа «Арча хәбәрләре»ндә чыккан язмаларны, язачак язмам героеның рәсемен дә җибәрде. Хөрмәтов Булат дигән егет ул. «Батырлык өчен медаль» белән бүләкләнгән. Әмма шунысы кызык: нинди батырлык өчен бүләкләнүен шактый вакыт белми йөргән. Арча педагогия көллиятендә укыган, музыка укытучысы булырга хыялланган Булатның күңеле ни өчендер хәрби хезмәткә тартыла башлаган. Озак уйлап тормый егет, академик ял ала да, контракт буенча армиягә китеп, хәрби разведкада хезмәт итә.

– Акчасына кызыктыңмы әллә? – дим.

– Юк, анда акча әллә ни күп түгел иде. Аның бит әле «Ватан сакчысы» дигән исеме бар, – дип елмая Булат.

Ул контракт буенча ике мәртәбә хезмәт иткән. Хезмәт итү дигәне, асылда, дөньяның төрле кыйтгаларына «сугышчан» командировкаларга йөрүгә бәйле. Икенче контракт тәмамлана гына Булатның, Украинада махсус хәрби операция башлана. Ул тыныч кына өенә дә кайтып китә алган булыр иде, әмма намусы кушмый. «Намус» дип әнә шундый «кәҗүнний» сүзләр яздым үзе, ә Булат моны гади генә итеп: «Авыр чакта егетләрне ташлап китәсе килмәде, хезмәттәшләрем белән тәмам туганлашып беткән идек», – ди. Контрактны бераз озайту өчен, командирына да бара Булат һәм үз теләгенә ирешә. 24 февраль көнне үк аларга сугыш кирәк-яраклары бирәләр һәм Булат хезмәт иткән мотоукчы бригада 4–5 көн эчендә Киевка барып җитәргә тиеш була. Тик егетләрне һәр торак пунктта диярлек Украина солдатлары ут ачып каршы ала. Булатның сөйләүләреннән аңлашылганча, Украина сугышка алдан ук әзерләнгән. «Хәтта авыл өйләрен дә ныгытмаларга әйләндергәннәр иде. Безне куркып борылып китәрләр дип өметләнгәннәрдер инде, бөтен җир «Җәһәннәмгә рәхим итегез!» дигән язулар белән тулган иде», – ди Булат.

– Җәһәннәмгә кердегез инде?

– Кердек. Безне юл буе гел утка тоттылар, авыл-бистәләрне милләтчеләрдән чистарта-чистарта алга бардык. Украинада фашистик пропаганда шулхәтле көчле алып барылган, хәтта авылларда да милләтчеләр төркемнәре оештырылган иде.

– Милләтчеләр икәнен каян беләсең?

– Тәннәрендә фашист татуировкалары иде. Телевидение аша пропаганданы әйтеп тә торасы юк. Бер авылда каршыбызга карт кына әби чыкты да: «Балалар, исән каласыгыз килсә, безгә сатылыгыз! Әнә телевизордан Зеленский сөйләде, корал белән әсирлеккә бирелгән кешегә – биш миллион, коралсыз бирелгән кешегә өч миллион сум акча вәгъдә итә», – дип сөйләнә башлады. Көләсе килә генә бит: «Әби, бар, өеңә генә кер дә утыр инде», – дигәч, агитатор әби: «Ярый, балалар», – диде дә китеп барды тагын. Бу вакыйга Украинадагы патриотизмның шактый ук дәрәҗәдә акча белән бәяләнүенә бер дәлил иде. Ә халык безне коткаручылар дип каршы алды.

Булаттан нинди батырлык күрсәтүе турында тагын төпчендем. Уңайсызланды егет, тәмам аптыраттың инде, дигән сымак миңа карап алды һәм батырлык шул түгел микән дип шикләнә-шикләнә, бер бәрелеш турында сөйләде.

Кыскасы, Киевка барып җитәргә утыз чакрым тирәсе ара калгач, боларга «кире борылырга» дигән фәрман килә. Имеш, Украина белән ике арада ниндидер килешү төзелергә тиеш. Әмма килешү дигәннәре юк нәрсә булып чыга, чигенгәндә боларны юл буе утка тоталар. Берсендә вертолетлар һөҗүм итә. Егетләр бөтен кораллардан ут ачалар, дүрт вертолетның дүртесен дә юк итәләр, бер БТРны да яндыралар. Булат «Батырлык өчен медаль» шул бәрелеш өчен бирелмәде микән дип шикләнә. Бүләкләнү турындагы хәбәрне дә узган җәй, контракт вакыты бетеп, Арчага кайткач кына ишетә ул.

Без аның белән патриотизм турында да сөйләштек, тегеләй дә, болай да төрле сораулар биреп карадым, әмма Булат бары тик: «Патриотизм хисе һәркемдә дә бар инде ул», – дип кенә куйды. Күпмилләтле илдә яшәвенә дә сөенә иде егет. Төрле халыклар арасында күпме дусларым бар бит, дип горурлана. Мондый сүзләрне авызыннан тартып алмадым, үзе әйтте.

Инде язмамны ничек тәмамлыйм икән дип утырганда, район башлыгы Илшат Нуриевның: «Мин ил иминлеге өчен яуга киткәннәргә берни дә кызганмаячакмын, нинди яхшылык эшли алам – барысын да эшләячәкмен», – дигән сүзләре искә төште. Бу сүзләргә аңлатма бирүнең кирәге юк.

«Ялгыз кайгы – кайгымыни,
Илгә кайгы килмәсен...» –
дип юкка гына җырламыйбыз шул без.

Риман ГЫЙЛЕМХАНОВ

Хәтер-хатирә

Соңгы басма

Үзе әзерләп калдырган соңгы кулъязма. Казанда Роберт Миңнуллинның «Мәхәббәтле көзләрем» дип исемләнгән яңа китабын тәкъдим итү кичәсе узды. Китапта шагыйрьнең басылып өлгермәгән яңа шигырьләре һәм элегрәк язылган сайланма әсәрләре урын алган.

– Бүген – шатлыклы да, шул ук вакытта сагышлы да көн. Халык шагыйре, остаз, дустыбызның җыентыгы дөнья күрде. Бу гади генә җыентык түгел, Роберт абый үз куллары белән әзерләп калдырган соңгы басма. Ул ничек бар, шулай басылды. Бик саллы, якты, җылы җыентык булып чыкты. Роберт абый һәрвакыт безнең күңелдә. Аның әйткән сүзләре, язган әсәрләре, елмаюы, шаярулары һәрвакыт безнең белән, – диде Татарстан китап нәшрияты баш мөхәррире, шагыйрь Ленар Шәех.

Роберт Миңнуллинның хатыны Клара ханым бу китапның шагыйрьнең туган көненә зур бүләк булуын әйтте:

– Быел Робертның арабыздан китүенә 3 ел булды. Әле кичә генә шикелле... 1 августта аның туган көне. Үзе исән булса, 75 яшьлек юбилеен зурлап уздырыр иде. Әлеге китапның чыгуы аның юбилеена зур бүләк булды. Робертның бу китапны ничек әзерләгәне әле дә исемдә. 700 битлек саллы китап булып чыгар дип уйламагандыр да ул. Кызганыч, үзе күрә алмады. Китап электрон вариантта да чыкты. Дөресен әйтергә кирәк, мин аны чын китап дип күз алдына китерә алмадым. Китап ул тере организм шикелле. Шуңа кәгазь вариантта чыгуын бик көттем.

Күз яшьләрсез укып булмый. «Мәхәббәтле көзләрем» китабы турында Клара Миңнуллина әнә шулай диде:

– Китап гел янымда, үзем белән дә йөртәм. Әмма ачып, рәхәтләнеп укый алмыйм. Мин Робертның күп кенә шигырьләрен нинди вазгыятьтә, нинди кәеф белән, нинди вакыйгалар турында язылганын беләм. Аларны уку авыр әле миңа. Көз турында шигырьләре бик күп. Ул – табигать күренеше генә түгел, Робертның күңел халәте. Сагышы да, моңлануы да, сагынуы да бар.

Гомере буе китапка сәнгатьчә якын килеп эшләде, аның белән яшәде. Роберт Миңнуллинның энесе, Галимҗан Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм сәнгать институты җитәкчесе Ким Миңнуллин абыйсы турында шулай дип искә алды:

– Роберт абый һәр нәрсәне яратып башкарды. Ул гомере буе китапка сәнгатьчә якын килеп эшләде, аның белән яшәде. Аның беренче шигырьләр китабы 1976 елда дөнья күрде. 110нан артык китап аның кулы аша узып, дөньяга таралды. Абыйның 80нән артык шигырьләр китабы бар. Минем исәпләвем буенча, монысы 82нчесе дип беләм.

Кичәдә күп кенә танылган татар шагыйрьләре һәм язучылары да катнашты.

– Роберт абыйның шигърияте татар халкының язмышына әйләнде. Мин бу китапны укып, өйрәнеп чыктым һәм шуңа инандым: шагыйрь киткәч, аның иҗаты башкача яңгырый башлый, ниндидер бер илаһи мәгънә ала. Роберт абыйның китүе – безнең өчен зур югалту. Тик шул ук вакытта ул мәгънәви көч бирә, әдәбиятыбызны көчәйтә, безне киләчәккә, мәңгелеккә алып бара, – диде язучы, шагыйрь Галимҗан Гыйльманов.

Ләйсән САФИНА

«Татар-информ»

Спорт хәтерен саклаучы

Татарстан спортчыларының уңышларын мәңгеләштергән кеше ул! Татарстанның спорт музее җитәкчесе Асия Яруллинаны әнә шулай дип искә алалар. Гомеренең соңгы ике дистә елын республика спортының тарих сәхифәләрен барлауга багышлаган Асия ханым 3 апрельдә озакка сузылган авырудан вафат булды.

Хезмәт юлын 1968 елда инструктор-методист буларак башлый ул. Хезмәт ветераны, Татарстанның атказанган физик культура хезмәткәре Асия Мәхмүт кызына җитәкче вазыйфаларын да ышанып тапшыралар. Ә 2003 елдан аны Казандагы Спорт сараенда урнашкан спорт музее җитәкчесе итеп билгелиләр. Аның идеясе һәм тырышлыгы белән музейда Татарстан олимпиячеләренә багышланган Олимпия даны залы барлыкка килә.

– Спортчыларыбызның казанышларын мәңгеләштерү һәм яшь буынны яңа үрләр яулауга этәрүдә гаять зур эш башкарды ул. Асия Мәхмүт кызы спорт музеен булдыруга һәм үстерүгә зур өлеш кертте. Хәзерге вакытта музейда саклана торган экспонатларның күпчелеге – аның шәхси өлеше, – дип искә ала аны Татарстан спорт министрының беренче урынбасары Хәлил Шәйхетдинов.

Асия Яруллинаның республикада инвалидлар өчен физкультура-спорт оешмалары барлыкка килүдә дә, «Уңыш» физкультура-спорт җәмгыяте төзелүдә дә өлеше зур. Соңгысы исә авылларда яшәүчеләргә, милли спорт ярышларына игътибарны арттыра.

– Аның кебек тырыш, эшчән һәм ярдәмчел кешеләр эштә генә түгел, тормышта да алай ук күп очрамый. Шуңа күрә Асия Мәхмүтовнаның туганнары һәм якыннары, хезмәттәшләре һәм танышлары аны һәрвакыт абруйлы, хезмәт сөючән эшче һәм җитәкче, бәхетле әни һәм әби буларак хәтерендә калдырыр, – ди Хәлил Шәйхетдинов.

УРМАНЧЫ ЯШЕЛЛЕК КӨТӘ

Табигать сагында

Яңгыр явып, үләннәр күтәрелеп китсә, урманчылар иркен сулыш алыр иде. Алар табигатьнең тизрәк яшелләнүен көтә. Тик әлегә көннәрнең җылы торуы, язның иртә килүе мәшәкать тудыра. Узган ел шушы вакытта коры үләнгә ут кабуның 2 очрагы теркәлгән булса, бүген аларның саны – 85. Әнә шуңа да урманчылар сак булырга, коры үләнгә ут төртмәскә, учак якмый торырга киңәш итә.

minleshoz.tatarstan.ru

– 2022 елда урманнарда янгынга каршы көрәш режимы 25 апрельдә кертелгән иде. Быел карның тиз эреп бетүе, көннәрнең җылы торуы сәбәпле, әлеге режимны 1 апрельдән керттек. Башкача мөмкин түгел. Үзебез сакламасак, урманнарны кем саклар? – ди Республика урман-янгын сүндерү үзәге җитәкчесе Айдар Гайфуллин. – Көннәр җылыну белән күңел ял көтә. Шулай да, табигатькә чыккач, учак якмый торсагыз иде. Әлегә урманнарга ут кабу куркынычы югары. Әлки, Чистай, Мамадыш районнарында инде урман янәшәсендәге полосаларга ут капты. Коры үлән тиз янып китә. Әле ярый республика урманчыларының янгынга каршы тору өчен махсус техникалары җитәрлек.

Техника дигәннән, урманчылар аларны журналистларга да күрсәтте. «ВТ» хәбәрчесенә янгын сүндерер өчен урманда машина белән үтә алмаган җиргә керүче тракторны йөртеп карарга да насыйп булды. Биредә алар җитәрлек. Барысы да үзебездә җитештерелгән. Квадроцикл да, «ГАЗ-53» машиналары да, янгын сүндерү «КамАЗ»лары да сафта тора. Бер теләк: кирәкләре чыкмасын иде. Янгынны булдырмас өчен урманчылар тәүлек буе кизү тора. Алар җәяү дә йөри, вертолетлар белән дә күзәтәләр. Буй җитмәгән, үзләре керә алмаган урыннарга квадрокоптер җибәрәләр. Кыскасы, урманчылар әзерлекле.

Айдар Гайфуллин, кайбер техникаларны, янгын сүндерү җиһазларын кулланганыбыз юк, ди. Булмасын да. Урманнарга ут тимәсен.

– Республикада төрле типтагы 25 урман-янгын сүндерү станциясе эшли. Алар республиканың төрле районнарында урнашкан. Шулай ук бездә янгынга каршы кирәк- ярак белән тәэмин ителгән 14 склад бар. Урман янәшәсендә яну очраклары булганда безнең үзәккә хәбәр килеп тора. Диспетчер аны шул урынга җаваплы урманчыга хәбәр итә. Әлеге утны тиз арада сүндерәбез, – ди Айдар Гайфуллин. – Урман янгынын ике төрле ысул белән сүндерәләр. Беренчесе – урынга су сибү, икенчесе – яна торган урманга каршы ут төртү. Бу очракта ике яктан килгән ут бер-берсе белән очрашып сүнә. Карактан кала, уттан юк, диләр. Шуңа без янгыннар булмавын телибез. Бу чорда, бар көчебезне куеп, йокыны онытып, табигатьне саклыйбыз.

Тырышлык бушка китмәгән. Узган ел Татарстан урманнарында янгын булмаган. Аның каравы 2021 елда 19 янгын теркәлгән иде. Урманчылар, ут үзеннән-үзе капмый, ди. Аларның 90 проценты кеше гаебе белән килеп чыга. Калган өлеше аунап яткан пыяла кызудан, яшен сугудан булырга мөмкин. Урманчылар бу язда корыган агачларны яндырмый торырга киңәш итә. Айдар Гайфуллин аларны бер урынга өеп, черетергә куегыз дип киңәш бирә. Шашлык пешерми торуны да сорыйлар. Кыскасы, урманга якын урнашкан җирләргә кермичә торуың хәерлерәк.

Гөлгенә ШИҺАПОВА

САН

Янгынга каршы режим кертелгән вакытта куркынычсызлык кагыйдәләрен бозган очракта кешеләргә **15** меңнән **30** мең, вазыйфаи затларга – **30** меңнән **50** мең, юридик затларга **100** меңнән **400** мең сумга кадәр штраф каралган.

КАЙГЫ УРТАКЛАШУ

2023 елның 6 апрелендә Татарстан Республикасының атказанган укытучысы, Татарстан Республикасы һәм Россия Федерациясенең мәгариф отличнигы, Каюм Насыйри исемендәге премия лауреаты, татар телендә белем бирүче мәктәпләрнең башлангыч сыйныфлары өчен татар, рус телләре һәм уку китаплары авторы, педагогика фәннәре кандидаты **ЯГЪФӘРОВА Рәдинә Хәким кызы** бакыйлыкка күчте.

Без – Татарстан Республикасы Мәгарифне үстерү институты хезмәткәрләре һәм ветераннары мәрхүмнең якыннарының, күпсанлы шәкертләренең олы кайгысын уртаклашабыз.

Рәдинә Хәкимовна башкалабыз Казанда эшләде һәм яшәде, әмма гомере буе Пермь краеның Байавылындагы туып-үскән нигезен төзек итеп саклауга зур әһәмият бирде, аны илһам чыганагы, иң зур кыйммәт итеп исәпләде. Соңгы мизгелләренең газиз нигезендә, якын кешеләре янәшәсендә уздыру бәхете – матур яшәешенең әҗер савабыдыр...

Ул безнең күңелләрдә сүзе һәм кылган гамәле белән һәрвакыт ихлас, ачыктан-ачык була белгән; гыйлемле һәм иманлы укытучылар укытучысы, милли мәгариф үсешенә зур өлеш керткән затлы шәхес булып яшәр. Урыны җәннәттә булсын!

«Ватаным Татарстан» газетасының махсус проекты Татарстанда яшәүче төрле милләтләрнең традицион уен кораллары белән таныштыра. Аның чираттагы чыгарылышын ДУМБРАга багышлыйбыз. Әлеге уен коралының күп кенә төрки халыклар арасында киң таралуы билгеле. Бүген без аның үткәне, бүгенгесе һәм киләчәге турында сөйләшербез.

Милли аккорд

МАХСУС ПРОЕКТ

ДУМБРА ЯСАУ ОСТАСЫ ҖӘЛИЛ ВИЛДАНОВ: «ӘЛЛИ-БӘЛЛИ»ДӘН БАШЛАНА»

Биектау

Халык уен коралларының язмышында үз телебездә җырланган бишек җырларының да өлеше бар. Танылган агач остасы, төрле уен кораллары ясаучы Җәлил ВИЛДАНОВ шулай ди. Биектау районының Коркачык авылында үз остаханәсен булдырып, агачтан ниләр генә ясамый ул. Без исә, оста янына кунакка барып, думбра ясау серләрен белештек, әлеге уен коралының язмышы хакында әңгәмә кордык.


Автор фотосы

:: Җәлил абый, сезне күпләр агачтан төрле җиһазлар ясаучы буларак белә. Думбралар һәм, гомумән, уен коралары ясау белән ничә еллап шөгыльләнәсез инде?

– Мактанырлык «стаж»ым юк әле. Гомумән, бу юнәлештә эшләргә өч еллап элек улым этәрде. Бугаз җырлавы белән мавыга ул. Мин аңа думбра ясап бирдем. Ярыйсы гына килеп чыккач, кызык булып китте, өйрәнүләремне, эзләнүләремне дәвам иттем. Думбра ясауның төрле ысулларын сынап карадым, үз ысулларымны уйлап таптым. Әйтик, думбраны ат тиресе тарттырып ясап карадым. Моңарчы мондый технологияне кулланган кеше юк иде әле. Гомумән, мине шушы юлга кертеп җибәргәне өчен улыма бик рәхмәтле мин. Ул әйтмәсә, әле дә сандыклар белән утырыр идем. Күпме иҗади ачышлар ясадым һәм әле дә ясап торам. Өстәвенә инструмент ясаганда да улымның өлеше бик зур. Думбраны лаклау, кылларын тарттыру – аның өстендә.

:: Ә думбра ясауның нечкәлекләрен кемнән өйрәндегез?

– Кулыма думбра алып, аны яхшылап карадым да, калганын төрле чыганаклардан өйрәндем. Мин белгәннәр барысы да интернетта бар. Теләгән һәм сәләте булган һәркем өйрәнә ала. Билгеле, эшләү рәтен читтән карасам, технологиясен үзем уйлап чыгарам.

:: Думбра сорап килүчеләр күпме? Гомумән, думбрачылар бармы бүген?

– Бик сирәк. Саный башласаң, кулдагы бармаклар да җитә. Татарстанда думбра турында ишетеп белмәүчеләр дә шактый ул. Бездә бит телевизорны ачсаң, гармун йә классик уен коралларында уйныйлар. Әйе, этник фестивальләр уза, ниндидер чараларда, ябык күргәзмәләрдә катнашабыз, ләкин аны халык күрми кала бит. Ә бүген аңа нәкъ менә борынгы уен коралларының тавышы җитми. Аның аңында, канында моңа рухи ихтыяҗ бар, ул ихтыяҗны бары уятырга гына кирәк. Моның өчен борынгы уен коралларын сәхнәгә күтәрергә, телевидение һәм башка чаралар аша халыкка ишеттерергә кирәк. Әйтик, ни өчен Сабан туйларында гармун тавышы гына ишетелә? Узган елның җәендә Казанда «Культурный код» дигән чара узды. Бер атна дәвамында узган ярминкәдә без дә катнаштык. Шунда шактый гына кеше, мин ясаган уен коралларын күреп, алар белән кызыксынды. Әлеге дә баягы думбраның төрки халыклар, шул исәптән татарлар арасында киң таралганын белгәч, шаккатучылар да күп булды. «Ничек оныттырганнар моны?» – дип аптырады кайберәүләр. Безгә, иң элек, менә шундый кешеләрне киметергә иде. Шуннан соң уйнарга өйрәнергә теләүчеләр дә артыр.

:: Ә сезнең кебек думбра ясаучылар бармы әле тагын?

– Дөресен әйтәм, мин булганнарын да белмәскә мөмкин. Шәхсән күргәнем булмаса да, Әлмәттә бер оста бар дип беләм. Башкортстанда яшәүче бер оста белән таныш мин.

Узган ел Әлмәттә узган «Каракүз» этнофестивалена Казахстаннан думбра ясау осталары, думбрачылар килгән иде. Билгеле булганча, анда бу уен коралы бик киң таралган, әле дә популяр. Ләкин шунысы мөһим: казахлар, дөресрәге, тарихны яхшы белгән казахлар думбраны үзләренең уен коралы дип атамый, ә төрки халыкларныкы, ди.

:: Соңгы арада гореф-гадәтләр, милли традицияләргә карата игътибар артты. Сез моны сизәсезме?

– Дәүләт игътибары турында әйтүеңдер инде. Сизелә ул, ярдәм дә бөтенләй күрсәтелми, дип әйтеп булмый. Үзе башкарган эшнең әһәмиятен аңлатып, тиешле программасын төзегән кешеләр бу ярдәмне грантлар рәвешендә ала. Дөресен әйткәндә, милли җанлы меценатлар ярдәме дә комачауламас иде. Кызганыч, андыйлар бик аз хәзер, гәрчә элек бу гадәти хәл булса да. Гомумән, безгә барыбызга да бер хакыйкатьне аңларга кирәк. Безнең буын милли уен коралларын саклауга ниндидер өлеш кертмәсә, балаларыбызга биреп калдыра алмаса, алар бөтенләй югалачак. Нәтиҗәдә татар мәдәниятенең бер бик зур өлеше юкка чыга дигән сүз. Моны күз алдына китерү дә йөрәкне әрнетә.

Татар моңсыз тора алмаган һәм тора алмаячак та.

:: Думбра ясау – керемле кәсепме?

– Әлегә юк. Әйткәнемчә, башта думбраны халыкка кайтарырга, бу уен коралында уйнаучыларны, уйнарга өйрәтүчеләрне арттырырга кирәк. Шуннан соң думбра алучылар да артачак. Сатып алучылар артса, бәясе дә төшәчәк. Әлегә думбраның бәясе 100–200 мең сум тирәсе. Думбра гына түгел, гомумән, уен коралларының бәясен «көйләү» өчен аларны зур масштабларда җитештерергә кирәк.

:: Думбраның язмышы кем кулында?

– Халык кулында. Бу очракта киңрәк фикерләргә кирәк. «Европалаштыру» чорында без үзебезнең татар булуыбызны онытмаска, татарлыгыбызны югалтмаска тиеш. Балаларыбызны «баю-бай» дип түгел, «әлли-бәлли» дип йоклата башласак та буладыр. Аларның аңына шул чакта ук сеңә башлый барысы да. Эшләмәслек эшләр түгел, думбраның да, милләтнең дә язмышы үзебездән тора.

ҖӘЛИЛ ВИЛДАНОВ ОСТАХАНӘСЕННӘН ВИДЕОРЕПОРТАЖ

Бу – кызык!

- Күп очракларда думбрада уйнаучы осталар әкиятчеләр булган.
- Алтын Урда һәм Казан ханлыгы чорларында ул хан-вәзирләр сарайларындагы әкиятчеләр һәм бәет әйтүчеләре даирәсендә киң таралган уен коралы булган.
- Татар халык мәкальләре арасында думбра белән бәйлеләре шактый. Әйтик, «Аңлаганга чебен тавышы да саз, аңламаганга думбра тавышы да аз», «Думбрачы думбрачыны күрсә, кылы өзелә, ди», «Туйда думбрага думбра белән, тукмакка тукмак белән кайтаралар», «Кызыңны үз иркенә куйсаң, думбрачыга барыр».
- Борынгырак думбраның кыллары ат койрыгы кылыннан эшләнгән.
- Узган гасырның танылган журналисты, җәмәгать эшлеклесе Әхмәтвафа Бәхтияров балачак хатирәләрендә әлеге инструмент турында болай дип яза: *«Аючылар авыл халкын җыяр өчен барабан суга, быргы кычкыртып йөри торган булганнар. Халык җыелып беткәч, аючылар аюларын думбра сугып, төрле такмаклар әйтеп биетәләр. Курайчылар курай уйнап, думбрачылар думбра сугып яшь киленнәрдән көлеп, чәнчеп, такмаклар әйтә торган булганнар. Аю биетеп йөрүчеләр дүрт-биш кеше булып, араларында курайчы, думбрачы, җырчы, такмакчы, көлдерүчеләре була».*
- Думбраның тугандаш уен кораллары – гөслә, канун, саз.

КАЗАХЛАР АША – ТАТАРГА

Алдагы әңгәмәдә думбраны халыкка кайтару юллары турында сөйләшә башлаган идек инде. «Риваять» этно төркеме җитәкчесе Руслан Габитовның да бу мәсьәләгә карата фикер-тәкъдимнәре бар.

Татарстанда думбрада уйный белүчеләр юк дәрәҗәсендә. Моның сәбәбен музыкант болай дип аңлата:

– Безнең думбрада уйнау традицияләре бик күптән – моннан 150–200 ел элек үк өзелгән. Шуңа өстәп, совет чорындагы милли мәдәниятка карата мөнәсәбәт тә йогынты ясый. Ләкин бүген бар да башкача. Киресенчә, милли мәсьәләләргә карата игътибар арткан чорда яшибез, – диде ул.

Аның фикеренчә, өзелгән традицияләрне яңарту өчен **думбра мәктәбе** булдырырга кирәк.

– Моның өчен тәҗрибәбез генә җитми. Безнең уйнау дәрәҗәсен «урамча» дип бәяләргә була. Моны ничек хәл итәргә? Күрше **төрки халыклардан өйрәнергә мөмкин**. Әйтик, казахлардан. Алардагы думбрага карата мөнәсәбәтнең нинди булуы билгеле инде. Казахлардан өйрәнеп, ул белемнәрне үзебезгә яраклаштыра алабыз. Аларда бит – дала. Ә бездә шәһәр культурасы өстенлек итә. Шулай итеп, икенче этап – мәдәниятебезгә яраклаштырып, билгеле бер **база булдыру.** Ягъни ноталар һәм башка теоретик материаллар, – дип аңлатты Руслан Габитов.

Бу юнәлештә икенче як та бар бит әле. Ул да булса – осталар.

– Осталар аз, әмма бар. Ләкин булганнары да эзләнү юнәлешендә. Шуңа да **осталар өчен дә билгеле бер калып** булдырырга кирәк. Татар думбрасы икәне күренеп һәм ишетелеп торырлык булсын. Әйтик, элеккеге сызымнардан татар думбрасының элмәге булу билгеле, – ди әңгәмәдәшебез.

Шуннан соң инде думбрада уйный белүчеләрнең санын арттыруны кайгыртырга була. Бу очракта **музыкаль мәктәпләр белән эшләү** – иң үтемле чараларның берсе.

– Әйтик, без – «Риваять» төркеме «Моң сандыгы» проекты кысасында районнарга чыгып, төрле мәктәпләрдә, балалар бакчаларында дәрес-концертлар оештырабыз. Балаларның кызыксынуы күзләреннән үк күренә. Ахырдан, килеп, «Минем дә думбрада уйныйсы килә, иртәгә үк музыка мәктәбенә язылам», – диючеләре дә очрый, – дип сөйләде Руслан Габитов.

Моңа өстәп, теле- һәм радиотапшыруларда, төрле концертларда думбра тавышы ешрак ишетелсә, халык һич югы мондый уен коралының барлыгын белер иде, ди ул.

– Милли үзаң дәрәҗәсе, халыкта кызыксыну арта башлады. Әмма боз кузгалды гына әле. Бу өлкәдә актив эшләвебезне дәвам итсәк, бәлки, 10–15 елдан гомумхалык кызыксынуы да барлыкка килер иде. Әмма бу энтузиастлар гына башкарып чыгарлык эш түгел…

БЕЛГЕЧ СҮЗЕ

Геннадий МАКАРОВ, сәнгать белеме кандидаты, Татарстан Республикасының атказанган сәнгать эшлеклесе, Казан дәүләт консерваториясе доценты

Думбра – Урта Идел җирлегендә яшәгән барлык этник төркемнәрнең сәнгатендә күп гасырлар буена лаеклы урын алган музыка коралы. Думбра иң борынгы уен коралларының берсе булып санала, әмма XIX йөз уртасында татар сәнгатендә кулланыштан төшеп кала. Хәзерге көндә аңа карата кызыксыну артты, ул кулланышка кайта башлады.

Думбраны өйрәнүгә мөһим өлеш керткән хезмәтләр арасында бу уен коралларының схемалары сызылган кулъязма нөсхә бар. Ул – күренекле фикер иясе һәм дин әһеле Таҗетдин Ялчыгол (1769–1839) сызымы. Бу кулъязманы мәшһүр татар археографы Альберт Фәтхи Татарстанның Сарман районыннан табып алып кайта. Корал сызымы аңлатмасы гарәп телендә язылган.

Урта Идел буенда яшәүче халыкларның музыкаль мирасы XIX гасырның икенче яртысыннан соң гармун белән көйләүгә җайлаша башлый, әмма борынгы этник көйләрне думбрада башкару алымнары да бөтенләй үк юкка чыкмый. Хәзер исә кыл-кубыз, гөслә, шулай ук думбрада уйнау сәнгате дә камилләшә башлады.

Тамашачы думбрачылык сәнгате белән кызыксына. Әлеге кызыксынуны югалтмас өчен бу коралда элекке заманда башкарылган әсәрләрне, дастан, тарихи бәетләрне барлау, думбра репертуарын булдыру, милли музыкаль тамырларны саклаган көйләрне табып өйрәнү кирәк.

Тагын бер мөһим мәсьәлә: күпләп думбралар ясау һәм халыкка җиткерү эшен җайга салу. Һәм, әлбәттә, башкарылган мондый эш нәтиҗәләрен мәдәнияткә, укыту-өйрәтү процессына кертү механизмнарын табу.

Борынгы думбра – XIX йөз уртасыннан алып Идел буендагы төрле этник төркемнәрнең: татар, чуаш, мари, удмурт, русларның музыкаль көнкүрешләреннән акрынлап югалып, төшеп калган корал. Мәсәлән, борынгы думбра җәдитчелек заманында татар мәдәниятенең гамәлдәге уен коралары исемлегенә керми кала һәм гамәлдән чыга. Русларның борынгы думбрасы урынына өч тимер кыл тарттырылган балалайка килә. Шундый ук алмашыну күренеше чуаш, мари, удмуртларда да күзәтелә. Башка кадим күренешләр белән бергә борынгы думбра фәкать тарихи мирас статусына ия булып кала.

XX йөз азагында татар, башкорт, нугай, чуаш, удмурт, мари, мордва, рус мәдәниятләрендә борынгы думбра коралына игътибар көчәйде, традицион фольклор стилендә иҗат итүче ялгыз башкаручылар да, заманча ансамбль формалары белән эшләүче белгечләр дә активлашты.

Себер төбәге татарлары фольклорында да думбра турында бай фактик материаллар бар. Аларны Себер музыкантлары актив куллана башлады. Моңа мисал итеп Төмән районы Чикча авылы мәдәният һәм ял үзәге каршында оештырылган «Шытыр-шатыр» фольклор-этнография коллективы иҗатын күрсәтергә мөмкин.

Урта Идел татарларының думбрасын музыкаль фән һәм фәнни-педагогик яктан өйрәнү, тергезү эше, 1980 нче елларда, думбраны югалтканнан соң йөз илле ел чамасы үтеп киткәч, Г. Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм сәнгать институтында башланып китте. Татар көйләрен башкаруны максат итеп куйган думбрачылар ансамбле дә беренче тапкыр 1986 елда шушы институтта төзелде. Шул ук елларда реконструкция, думбраларны кулдан ясау тәҗрибәсе дә башланды. Музыка коралларын ясаучы, ансамбльне оештыручы институтның фәнни хезмәткәре Геннадий Макаров булды.

Реконструкцияләнгән татар думбрасын гамәлгә кертү эшендәге тагын бер этап турында әйтү кирәк. Әлеге ансамбль җитәкчесе кулдан ясаган беренче думбра үрнәген «Сорнай» фольклор ансамбле җитәкчесе Ринат Гыйлаҗевка тапшырганнан соң думбра сәнгате яңа сулыш алды. Ансамбльдә думбралар куллану офыгы тагын да киңәйде һәм ныгыды. Думбра сәнгатен пропагандалауда һәм музыкаль-педагогик тәҗрибә туплауда 1991–1995 елларда Казан шәһәренең 13 номерлы татар гимназиясендә төзелгән махсус думбрачылар ансамбле дә шактый зур өлешен кертте.

Думбрачылар белән эшләү юнәлеше Казан дәүләт консерваториясендә, Абдулла Алиш исемендәге Балалар иҗаты сараенда «Ак калфак», «Бәрмәнчек», «Җомга көн» ансамбльләрендә һ.б. коллективларда да актив кулланыла башлады.

Алдагы көндә квалификацияле башкаручылар әзерләү һәм халык көйләрен, композиторлар әсәрләренең концерт вариантларын думбра белән башкару өчен яза алырлык иҗатчы-авторларны формалаштыру буенча да Казан консерваториясендә эш алып барыла.



Ике кыллы төрки думбраның фоторепродукциясе. Таҗетдин Ялчыгол кулъязмасы

Лилия ГЫЙМАЗОВА әзерләде

Баш мөхәррир – САБИРОВА Гөлнара Ильяс кызы
Газетаны оештыручылар: ТАТАРСТАН ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ, МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ, РЕДАКЦИЯНЕҢ ХЕЗМӘТ КОЛЛЕКТИВЫ
Газета Татарстан Республикасы Информация һәм матбугат министрлыгында 1995 елның 21 июнендә теркәлгән.
Теркәү таныклыгының номеры – 430.
Газета матбугат чараларының үзәк каталогына кертелгән.
Тираж – 5316 данә
Гомуми тираж – 14278 данә
Газетага сертификат бирелде Заказ 250

РЕДАКЦИЯ ҺӘМ НӘШЕР АДРЕСЫ
420097, Казан, Академия ур., 2 й. «Ватаным Татарстан» газетасы редакциясе.
www.vatantat.ru
info@vatantat.ru, vatantat@list.ru, vtreklama@mail.ru
89179270040
Индекс П2409 (гадәти сан – атнага дүрт тапкыр чыга)
П2448 (гадәти сан, пенсионерлар өчен)
П2449 (гадәти сан, оешмалар өчен)
П2435 (җомга саны)

ТЕЛЕФОННАР
222-09-70 – кабул итү бүлмәсе
222-09-67 – баш мөхәррирнең беренче урынбасары
222-09-73, 222-09-69, 222-09-65 – баш мөхәррир урынбасарлары
222-09-68 – авыл хуҗалыгы, фән һәм мәгариф
222-09-67 – дин, сәламәтлек
222-09-64 – әдәбият, сайт
222-09-66 – сәясәт, тәрҗемә, оператор, хатлар һәм социаль мәсьәләләр
222-09-65 – реклама бүлеге
222-09-72 – бухгалтерия
222-09-73 – компьютер үзәге
221-18-99 – газета килмәсә яки соңарып килсә

Оригинал макет **Jahat™** программалар пакеты ярдәмендә әзерләнде. Мәкалә авторларының фикерләре редакция фикере белән туры килмәскә мөмкин. Хатлар, кулъязмалар, рәсемнәр рецензияләнми һәм кире кайтарылмый.
R тамгасы куелган язмалар реклама буларак тәкъдим ителә.
N тамгасы куелган язмалар килешү нигезендә басыла.
Күчереп бастыру өчен редакциядән язмача рөхсәт алу шарт.
График буенча бу санга 20 сәгатьтә кул куелырга тиеш.
Кул куелды – 20 сәгатьтә.
Ваклап сату бәясе килешү буенча.
Газета «ТАТМЕДИА» АҖ филиалы «Идел-Пресс» полиграфия-нәшрият комплексында басылып чыкты **(420066, Казан шәһәре, Декабристлар ур., 2й.).**
16+